ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ISSN 0130-2418

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

№ 6 (353)
ИЮНЬ 2021

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

СӘЯХӘТ ӨЧЕН 20 ТӘКЪДИМ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

1001 ЛӘЗЗӘТ

Татарстанга туристик сукмак бик күптәннән салынган. Моннан өч йөз еллап элек, 1722 елның маенда, Персиягә юл тоткан рус патшасы Петр I Казанда 12 онытылмас «туристик» көн үткәрә – шәһәрне карап йөри, ул вакытта әле атамасына «иске» сүзе кермәгән татар бистәсендә була, борынгы Болгар хәрабәләрен күреп кайта, булачак Петропавел соборының нигез ташын сала һәм бер уңайдан сәүдәгәр Михляев йортында оештырылган төрледән-төрле сый-нигъмәтләрдән сыгылган бәйрәм табыны артында үзенең илле яшьлеген дә бәйрәм итә.

Императрица Екатерина II безнең якларда 1767 елның маенда кунак була. Казанда булган биш көн эчендә ул Кремльне, Богородица монастырен, Татар бистәсен карарга, 1 нче Казан ирләр гимназиясе укучылары куйган спектакльдә һәм Дворяннар җыенында оештырылган маскарадта булырга өлгерә һәм шәһәребез «зур патшалыкның башкаласы» булырлык дигән фикергә килә. Үзенең хөрмәтенә оештырылган барлык экскурсияләр һәм кабул итүләр әби патшага ошый: «шактый яхшы һәм үз өендәге кебек» дип нәтиҗә ясый ул һәм алга таба үзен «Казан алпавыты» дип атарга боера.

Соңрак, 1799 елның маенда, Павел I патша Казанга килеп, үз хөрмәтен күрсәтә. Ул шулай ук «император маршруты» буенча йөреп чыга – Кремль, Татар бистәсе, «борынгы хәрабәләр», «әкияти утрау»... Һәм тагын әле «Мәскәүнең үзендә дә күп булмаган әдәпле һәм зыялы затларны, бигрәк тә ханымнарны» табуы турында әйтә.

Кунакларга тагын нинди сәяхәтләр тәкъдим ителгән соң? 1858 елда Казанга килгән «Өч мушкетёр» авторы Александр Дюмага куяннар аулау ошый. Инглиз Эдуард Турнерелли 1839 елда Казан күренешләренә гашыйк була. Табигатьне өйрәнүче Александр Гумбольтның безнең якларга сәяхәте 1829 елгы Сабантуйга туры килә, һәм ул җирле халыкның кунакчыллыгына мөкиббән китә. Граф Лев Толстой гомумән ниндидер Неаполь һәм Венецияләргә караганда Мамадышны якынрак күрүе турында сөйли... Тегесе дә, монысы да, башкалары да – расланган тарихи фактлар. 1001 император, язучы, сәяхәтче, граф һәм башка туристик ләззәтләр – бүген дә Татарстанда бар. Сайлагыз, сәяхәт итегез һәм ләззәтләнегез!

Сезнең сәяхәтче редакциягез

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Ксения Сёмина
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото ТР Туризм буенча дәүләт комитетыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-1800
Басарга кул куелды: 18.06.2021
Басмадан чыкты: 24.06.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик татарстанда

РУС ХАЛЫК ҖЫРЫНЫҢ СҮЗЛӘРЕН КЕМ ЯЗГАН

Дөньяда иң үзенчәлекле һәйкәлләрнең берсе Казанда, «Электроприбор» заводы янындагы скверда урнашкан. Ул – ак каен. Һәйкәлгә беркетелгән истәлек язуында шагыйрь Нигъмәт Ибраһимов (1778–1818) – «Во поле березка стояла…» җыры текстының авторы хөрмәтенә дип тә куелган. Казан университеты адъюнкт-профессоры Нигъмәт Ибраһимов рус телен укыткан һәм шигырьләр язу белән мавыккан. Ул тагын бер «Вечером красна девица…» дип аталган рус халык җырының авторы. Әлеге танылган җырның мәкальгә әйләнеп киткән бер юлын һәр кеше беләдер: «С милым рай и в шалаше».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

«Татарстанда ял көннәрендә 1001 ләззәт»

4. Болгар: татар тарихы бишеге

12. Чистай: сәүдәгәрләр, язучылар һәм... диссидентлар

20. Балык Бистәсе: асыл боланнар һәм чуртан бургерлары төбәге

26. Мамадыш: безнең Париж

32. Байлар Сабасы: күңелле һәм бай

38. Кама Тамагы: күккә тоташкан диңгез

44. Алексеевск районы: тарихка изге ачкыч

50. Кукмара районы: күк таулар, алып имәннәр һәм... киез итек

56. Алабуга: үткәнгә сәяхәт

62. Арча районы: әкиятләр һәм Кыш Бабай иле

Сез күрергә тиешле вакыйгалар

72. Зөядә Май чабу бәйрәме Кыш белән яз саубуллаша торган урын

73. Спас ярминкәсе Остакуллар шәһәрчегенә сәяхәт

74. SUNNYFEST «Танк» белән алга!

75. «Бөек Болгар» Урта гасыр сугышлары фестивале Кылычлар, көбә күлмәкләр: үткәннәрдән сәлам

Сәяхәтләр турында тагын да тулырак мәгълүмат: protatarstan.ru

Татарстан буйлап автомобильдә!

82. Зөя утрау-шәһәренә барабыз һәм уникаль агач музеена керәбез

83. Элек шәһәр татарларының ничек яшәгәнен беләбез һәм милли сыйлардан авыз итәбез

84. Яр Чаллыда «Түбәтәйне» табабыз һәм Түбән Кама ГЭС фонында селфи ясыйбыз

85. Түбән Камада шәһәр тарихы музеена керәбез һәм, Манзара күзәтү тәгәрмәченә менеп, шәһәрне карыйбыз

86. Тәтештә гигант кырпы балыгы янында фотога төшәбез һәм арбалеттан атарга өйрәнәбез

92. Әлмәт якларына юл тотабыз һәм Сәмәркандның кайда урнашканын табабыз

2019 ИЮНЬ

Вилле Хаапсало, фин актеры һәм режиссеры, – ТР Тәтеш районында «Күпмәдәниятле Татарстан» тапшыруын төшергәндә:

– Мин төрле мәдәниятләр һәм халыклар, диннәр бергә яши алуын күреп сокланам. Татарстанда аш-су тәмле, Идел, балык. Финляндиядән күп сәлам!

2021 МАЙ

Леонид Слуцкий, «Рубин» командасының баш тренеры, – «Вечерний Ургант» телетапшыруында:

– Казан – топ. Барыгызны да Казанга чакырам! Иң шәп шәһәр. Шул ук Мәскәү, тик бөкеләрсез генә. Җир йөзендә идеаль урын.

2017 ОКТЯБРЬ

Нино Катамадзе, грузин джаз җырчысы, – Казандагы гастрольләре вакытында:

– Теге яки бу илгә килгәч, һәрвакыт күрергә тиешле урыннар була. Һәм Казан, Татарстан – шундый урыннарның берсе, монда үзенә күрә бер тирбәлеш сизелә. Дөньяда төрле мәдәниятләр, диннәр фантастик дәрәҗәдә бергә яши алган башка мондый урын юк. Бу сез яшәгән төбәкне тирәнрәк һәм зирәгрәк итә.

«ЯЛ КӨННӘРЕНДӘ 1001 ЛӘЗЗӘТ»

Алда безне җылы, ягымлы җәй көтә. Һәр ял көнен кызык, истә калырлык итеп планлаштырырга мөмкин. Туган ягыбыз шулкадәр матур, борылыш саен яңа ачыш көтәдер кебек. Һәр ял көне – актив һәм кызыксынучан сәяхәтчеләр өчен гарантияле 1001 ләззәт. Сезне тарихи ядкәрләргә бай уникаль истәлекле урыннар, гүзәллеге белән әсәрләндерүче табигать күренешләре, матур риваятьләр, тәмле-тәмле ризыклар көтә.

БОЛГАР:
ТАРИХ БИШЕГЕ

ЧИСТАЙ:
СӘҮДӘГӘРЛӘР, ЯЗУЧЫЛАР ҺӘМ... ДИССИДЕНТЛАР

БАЛЫК БИСТӘСЕ:
АСЫЛ БОЛАННАР ҺӘМ ЧУРТАН БУРГЕРЛАРЫ ТӨБӘГЕ

МАМАДЫШ:
БЕЗНЕҢ ПАРИЖ

БАЙЛАР САБАСЫ:
КҮҢЕЛЛЕ ҺӘМ БАЙ

КАМА ТАМАГЫ:
КҮККӘ ТОТАШКАН ДИҢГЕЗ

АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ:
ТАРИХКА ИЗГЕ АЧКЫЧ

КУКМАРА:
КҮК ТАУЛАР, АЛЫП ИМӘННӘР ҺӘМ... КИЕЗ ИТЕК

АЛАБУГА:
ҮТКӘНГӘ СӘЯХӘТ

АРЧА РАЙОНЫ:
ӘКИЯТЛӘР ҺӘМ КЫШ БАБАЙ ИЛЕ

PRESSA

1

БОЛГАР:
ТАРИХ БИШЕГЕ



Борынгы Болгар – юкка чыккан бөек дәүләтләр – Идел буе Болгарстаны һәм Алтын Урда тарихы варисы ул. Идел белән Чулман кушылган урында урнашкан кала инде X гасырда ук әһәмиятле мәдәни һәм сәяси үзәк була. 922 елда Идел буе Болгарстанында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителә. XIII гасырда биредә Алтын Урданың беренче башкаласы була. Биредә Кол Гали яши һәм иҗат итә. Соңрак Болгар хәрабәләрендә Пётр I, Екатерина II, Гавриил Державин, Александр Пушкин, Иван Шишкин, Габдулла Тукай һәм башка бик күп шәхесләр булып китә.

Бүген бу урта гасырлар мөселман төзелеш сәнгатенең дөньяда иң төньякта урнашкан ядкәре, XIII–XIV гасырлар уртасы болгар-татар архитектурасының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә кертелгән бердәнбер үрнәге. Әлеге территориянең мәдәни ландшафты мең ел дәвамында үзгәрешсез саклана. Иерусалим чокыры монголларга кадәрге заманнан бирле мәгълүм. Борынгы Болгар шәһәре калдыклары XIV гасыр ныгытмалары чигендә сакланган. Бүгенге Болгар шәһәре XVIII гасырда нигез салынган ныгытма эчендә урнашкан. Бай тарихи нигезне тыюлык территориясендә безнең көннәрдә пәйда булган һәйкәл һәм объектлар да бик күркәм тулыландырып тора. Мәсәлән, биредә Гиннесcның рекордлар китабына кертелгән дөньяда иң зур басма Коръән саклана. Бик күп уникаль экспонатлар куелган Болгар цивилизациясе музее исә текә яр рельефына кертеп төзелгән. Теплоходта килгән кунаклар пристаньнан туры шунда барып керә.

Ак мәчеткә 88 шәрык колоннасыннан торган ике анфилада алып бара.



Дөньяда иң зур басма Коръәннең үлчәме – 1,5х2 метр. 632 биттән торган китап Шотландиядә эшләнгән югары сыйфатлы бик чыдам кәгазьдә басылган.

Истәлекле урыннар

АК МӘЧЕТ

Тарихи Болгар шәһәрлеге янында изге гыйбадәтханә – 2012 елда төзелеп беткән Ак мәчет урнашкан. Гаҗәеп матурлыгы белән ул икенче бер атаклы мәчетне – Һиндстандагы Таҗ-Махалны хәтерләтә. Ак мәчеткә 88 шәрык колоннасыннан торган ике анфилада алып бара. Бөтен ансамбль кардай ак итальян мәрмәре белән тышланган. Зур намаз залы ике катлы итеп эшләнгән, беренчесендә – ирләр, икенчесендә нәфис сырлы агач пәрдә артында хатын-кызлар гыйбадәт кыла.

ДӨНЬЯДА ИҢ ЗУР КОРЪӘН

Шәһәрлек территориясендә алтын гөмбәзле ак таш бина урнашкан. Бу – Истәлек билгесе, Идел буе Болгарстанында ислам динен кабул итүгә багышланган музей. Биредә дөньяда иң зур басма Коръән саклана. Аның үлчәме – 1,5х2 метр. Һәркайсы чирегешәр килограмм авырлыктагы 632 битлек китап Шотландиядә эшләнгән югары сыйфатлы бик чыдам кәгазьдә басылган. Бозау тиресеннән иләнгән күн тышлыгы алтын йөгертелгән көмеш һәм асылташлар белән бизәлгән: монда малахит пластиналары да, яшма, лазурит, циркон, топаз, аметист, мәрҗән, авантюрин да бар. Изге китапның авырлыгы 500 килограмм тәшкил итә.

РАБИГА КҮЛЕ

Шәһәрлек янәшәсендә берничә кечкенә күл бар, халык шул күлләрнең суын эчкән. Шулардан иң матуры – Рабига күле турында мондый риваять сөйлиләр: гүзәл хан кызы Рабиганың дуслары, аланга килгәч, аккошларга әверелә һәм шәһәр өстендә оча торган була. Бервакыт Рабига да сарайдан качып чыга һәм аккошка әверелә. Аудан кайтып баручы хан әлеге гүзәл аккошка җәясеннән ата. Күкрәгенә ук кадалган кызның үз баласы икәнен аңлап алган ханның ачы күз яшьләреннән әлеге күл пәйда була...



БОЛГАР ЯЗУЫ ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

Бу туры мәгънәсендә һәйкәлләр: Болгар дәүләтенең төрле чорларына караган язу үрнәкләре кабер ташларында эпитафияләр сыйфатында сакланып калган. Барлык плитәләр хәзер Төньяк төрбә эченә куелган. Гарәп һәм болгар телләрендәге язулар әлеге җирлектә яшәгән халыкның теле, укымышлылыгы, социаль хәле, дини юнәлешләре хакында сөйли. Мәсәлән, кабер ташына җирләнүченең исемен генә түгел, бәлки аның тугызынчы буынга кадәр шәҗәрәсен дә яза торган булганнар.

Фото: Дмитрий Зюкалин.



Үзенчәлеге

КАРА ПУЛАТ ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

Тыюлыкның иң истәлекле урыннары – күпчелеге шул замандагыча сакланып калган урта гасыр биналары. Җәмигъ мәчетенең кояшта уңган диварлары эчендә борынгы Болгар халкының моннан 800 ел элек бирегә намазга җыелуын күзаллавы бер дә кыен түгел. Ул чакта мәчет шәһәрнең төп корылмаларыннан берсе санала һәм дәүләтнең куәтен, исламның бөеклеген күрсәтергә, кунакларны үзенең зурлыгы һәм матурлыгы белән таң калдырырга тиеш була. Ул бүген дә элеккечә үк «көч урыны», беренче чиратта рухи көч чыганагы булып тора. Нәкъ менә биредә ел саен Изге Болгар җыены үткәрелә, анда Татарстаннан һәм башка төбәкләрдән меңнәрчә мөселман җыела. Җәмигъ мәчетенең чордашлары – Кече манара, Хан төрбәсе, Шәрык пулаты, яки Хан мунчасы. Әлеге корылмалар урта гасырлар Болгар дәүләте тормышындагы мөһим дәвер хакында сөйли.

Тыюлыкның төрле өлешләрендә нигезләре табылган Төньяк һәм Шәрык төрбәләре, Кара пулат, Ак пулат, мунчалар, мавзолейлар XIV гасырда төзелгән. Алтын Урда ханнарының үзара сугышлары һәм күрше дәүләтләр белән дошманлыгы чоры хакында берничә риваять сакланган. Алардан берсе серле Кара пулатка бәйле. Аксак Тимернең Болгарга һөҗүме вакытында Габдулла хан гаиләсе һәм яраннары белән әлеге бинада яшеренгән, имеш. Илбасарлар корылмага ут төрткән. Кара төтен болыты таралгач, бина түбәсендә ап-ак киемнән бик гүзәл кыз, хан кызы пәйда була. Гүзәллегенә таң калган Аксак Тимер аны хатынлыкка алмакчы була, әмма кыз баш тарта. Ярсыган әмир Габдулла ханның ике улын үтерергә боера. Хан кызы, әгәр туганнарын аяса, әмирнең хатыны булырга вәгъдә бирә. Туганнарына яхшы атлар биреп иреккә җибәрүләрен күргәч исә, хан кызы пулат түбәсеннән сикереп һәлак була.

Галимнәр, Кара пулатта нәрсә булган дип, әлегә кадәр баш вата: казый йортымы, мәчет яки мәдрәсәме, илгизәр дәрвишләр өчен ханәкә булганмы ул – билгесез.

Кайвакыт Борынгы Болгар кунаклары өчен уханы Болгар музей-тыюлыгы директоры Рамил Җиһаншин үзе пешерә. Ул бу эшнең чын остасы.

Тәмлетамакларга

ХАННАР СЫЕ

Җирле тарихчылар әйтүенчә, Болгар ханына уханы махсус рецепт буенча пешергәннәр. Бәхеткә, ул безнең көннәргә кадәр сакланган, һәм аш бүлмәсеннән чыкмыйча гына да без үзебезне бераз хан итеп тоя алабыз. Тиңе булмаган ризыкны әзерләү өчен балык (җәен, сыла, кызыл балык, чөгә балыгы – берәм-берәм түгел, барысы да бергә), тавык, бәрәңге, кишер, суган, тоз, борыч, сөт өсте, дәфнә яфрагы кирәк. Әзерләү процессы үзе дә шәрык экиятен хәтерләтә. Башта тавыкны пешерәләр. Аны алгач, шулпага чистартып туралган җәен, сыла, чөгә балыкларын салалар. 10-15 минуттан балыкны алып, шакмаклап туралган бәрәңге, бөҗралап туралган суган һәм түгәрәкләп туралган кишер салалар. Яшелчәләр пешеп чыгарга җиткәч, шулпага кызыл балык кисәкләрен, кара борыч, дәфнә яфрагы өстиләр. Иң ахырда сөт өсте салына. Ул оеп төшмәсен өчен, башта бераз җылытып алырга кирәк. Телеңне йотарлык уха килеп чыга! Хан пешекчесе үз эшен яхшы белгән. Сый-хөрмәтне шундый тәмле ризыктан башлагач, лаеклы итеп төгәлләргә дә кирәк бит инде. Табынга бал-май куелган. Әлеге бик гади тоелган ризыкның да сере бар икән, аны музей-тыюлыктагы махсус мастер-класста ачалар. Гомумән, Болгарда сыйлана беләләр. Инде берничә ел буе биредә «Чәк-Чәй» фестивале уздырыла. Теләгән һәркемне төрле җитештерүчеләр пешергән чәкчәк белән сыйлыйлар, ә аннары кайсының тәмлерәк икәнен ачыклыйлар. Бер үк вакытта кунакларны әлеге милли тәм-томны әзерләү серләренә дә өйрәтәләр.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Шәхси автомобильдә. Казаннан Болгарга кадәр юлга (200 км чамасы) 2,5–3 сәгать вакыт китә.
Казан–Болгар автобусында. Казанның үзәк автовокзалыннан китә. 3 сәгать 40 минут бара.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Болгарда кесәңә карап төрле урын сайларга була – 1900 сумнан 22800 сумга кадәр торган ике кешелек номерлар тәкъдим ителә.

КАЙДА СЫЙЛАНЫРГА:
Балыктан тыш, Болгарда тагын бик тәмле белен белән дә сыйланырга була – тыюлык территориясендә дә, шәһәрдә дә. Ашаганда пейзаж белән хозурланырга яратучылар исә Болгар цивилизациясе музее ярусларының берсендә урнашкан «Зөләйха» кафесын сайлый ала.

СУВЕНИРЛАР ҺӘМ КҮЧТӘНӘЧЛӘР:
Болгардан нинди дә булса тәмле ризык алып китәргә кирәк. Мәсәлән, Спас пешекчеләренең атаклы рецепты буенча әзерләнгән балык, хәләл ит һәм казылык, яңа гына мичтән чыккан икмәк һәм хуш исле татлы нигъмәтләр һәркемнең күңеленә хуш киләчәк.

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Болгар музей-тыюлыгы территориясендә урнашкан Болгар цивилизациясе музеенда алырга була.

2

ЧИСТАЙ: СӘҮДӘГӘРЛӘР, ЯЗУЧЫЛАР ҺӘМ... ДИССИДЕНТЛАР

Чистай – музей-шәһәр ул, биредә чорлар бер-берсенә үрелеп яшәвен дәвам итә. Биредә борынгы Болгар ныгытмасы Җүкәтау сәүдәгәрләр мәдәнияте күршесендә тора. Бөек Ватан сугышы елларында илнең әдәби башкаласы булган шәһәр исә 1970 нче еллардагы диссидентлык хәрәкәте белән «янәшә» атлый.

Тарихи туристлыкны яратучылар өчен чын хәзинә бу. Шәһәр үзәгенең планировкасы Екатерина заманыннан бирле сакланып калган, җыйнак кына сәүдәгәр йортлары күзне иркәли, 150 ел элек утыртылган Скарятин бакчасы эссе көннәрдә үзенең күләгәсендә рәхәтләнеп ял итәргә дәшә...

Кайчандыр Чистайдагы бу юлларда Борис Пастернак сәйран кылып йөргән. Ерак офыкны күзәтә-күзәтә, елга һавасын сулаган. Пароходка утырып, бу дөньяда үзенең соңгы тукталышы булачак Алабугага киткән Марина Цветаева хакында уйланган. Фронтка китеп барганчы, Александр Гладков белән фикерләшкән һәм яңалык алмашкан... Нәкъ менә биредә, вакыт бөтенләй кагылмагандай тоелган Үзәк китапханә бинасында, Пастернак үзенең атаклы «Кышкы төн» шигыренең беренче юлларын укыган. Әйе, сүз дә юк, Чистай – гаҗәпләндерә һәм моңсуландыра, сөендерә һәм илһамландыра торган урын.

Ә инде тыныч урамнар буйлап сәяхәт итүгә мәһабәт Чулман буйлап катерда йөреп кайтуны да өстәсәң, бу урынга гашыйк булуыңны көт тә тор. Әнә ничек матур булып ялтырый елга кояш нурында! Янәшәсендә исә «Кама яр буе» заманча паркы җәйрәп ята, андагы челтәрле чатыр-ротондалар, фонтан каскадлары, шәһәр сәгате, Никахлашучылар аллеясе һәм Мәхәббәт агачы үзләренә тартып тора...

Кайчандыр Казан сәүдәгәре Подуруевның җәйге резиденциясе булган әлеге ике катлы тарихи бинада чын «вакыт машинасы» саклана.

Истәлекле урыннар

ШӘҺӘР ТАРИХЫ МУЗЕЕ

800 еллык очлым, 1902 елда «юнылган» агач велосипед, болгар көбәсе, мамонт сөякләре, бизонның казык теше... Бу музейны моннан нәкъ йөз ел элек төбәкне өйрәнүче һәвәскәр, натуралист Александр Булич ачкан. Кайчандыр Казан сәүдәгәре Подуруевның җәйге резиденциясе булган әлеге ике катлы тарихи бинада чын «вакыт машинасы» саклана. Борынгы Җукәтау ныгытмакаласына барасыгыз киләме? Рәхим итегез! Әллә Чулмандагы борынгы шәһәрчек үзенә тартамы? Бик рәхәтләнеп шунда җибәрербез!

БОРИС ПАСТЕРНАК МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЕ

Шул ук өстәл, кара савыты, каләм. Биредә вакыт туктап калган. 1941 елда бу бүлмәне Борис Пастернак очраклы гына кулга төшерә. Ул хуҗаларга йортны кыш буе утын белән тәэмин итәргә вәгъдә бирә. Бик кыен булып чыга үзенә бу вәгъдәне үтәү... Хәер, менә дигән тәрҗемәче һәм исткитеч язучы булса да, Пастернак бернинди физик эштән дә курыкмый. Кичләрен исә самовар янында фатир хуҗасы Василий Вавиловның Гражданнар сугышы турында истәлекләрен тыңлый. Соңрак әлеге тәэсир-кичерешләре «Доктор Живаго» романының нигезен тәшкил итә.



ЧӘНЕЧКЕЛЕ ТИМЕРЧЫБЫК АРТЫНДА

Бүген илдәге иң борынгы пенитенциар биналардан берсе булган Чистай төрмәсе 1855 елда төзелә башлый. 160 елдан артыграк вакыт эчендә бу диварлар артынданиләр генә булмаган! 1978 елның 8 октябреннән төрмә тарихында иң кызу вакыт башлана – ул «сәяси» статусын югалткан «Владимиркадан» эстафетаны кабул итә. Аеруча куркыныч дәүләт җинаятьчеләрен Мәскәүдән мөмкин кадәр ераккарак алып китәләр – Чистай төрмәсе шулардан берсе була.

Сүз уңаенда, Чистай казематларының сәяси блогында утыручылар арасында бик күренекле шәхесләр дә була: атаклы диссидент һәм сәясәт эшлеклесе Натан Щаранский; галим нейрофизиолог Владимир Буковский; киләчәктә Гарвард хокук мәктәбе профессоры булачак Михаил Казачков; Бөтендөнья психиатрия ассоциациясенең мактаулы әгъзасы табиб Анатолий Корягин; 90 нчы елларда РФндә кеше хокуклары буенча вәкил булачак Сергей Ковалёв һәм башка бик күпләр. Сәяси блокта берьюлы бер үк вакытта 15-17 кеше, иң күп дигәндә, 19 кеше генә утыра. Алар арасында бөтенләй үзгә арестант – гади Себер мужигы Анатолий Марченко аерылып тора, чит илләрдә ул хәтта Солженицыннан да популяррак була. Марченконың Хрущев һәм Брежнев лагерьлары турындагы «Мои показания» китабы Көнбатышта басылуга ук таралып бетә.

Тоталитар режимны гәүдәләндергән Чистай казематлары хакында сүз нәкъ менә Марченкодан бөтен дөньяга тарала. «Советлар Союзындагы барлык сәяси тоткыннарны азат итәргә!» дигән моңарчы күрелмәгән таләп белән ул 1986 елда вакыты чикләнмәгән ачлык игълан итә. Марченко 117 көн ач тора, ашый башлап 10 көн үткәч исә, җан тәслим кыла. Бу декабрь аенда була, бер айдан соң илдә сәяси тоткыннарны азат итүнең беренче дулкыны башлана. Сүз уңаенда, аларның соңгысы 1991 елда гына иреккә чыгачак. Бу Чистай тоткыны Михаил Казачков булачак.

КАМА ЯРЫНДА ТАМАК ЯЛГЫЙБЫЗ

Сыла, корбан балык, сазан, җәен, чуртан, алабуга, кәлчәк… Чулманда тотылган, ысланган балык кирәкме? Чистайга рәхим итегез! Шәһәрдә мондый балык сата торган урыннар бик күп. Әмма әлеге деликатесны яратучылар алдан ук кисәтеп куя – алданрак хәстәрен күрү мәслихәт. Чулман аша күперне чыккач, Алексеевское бистәсенә барып җиткәнче, стихияле базарны күрерсез. Анда балыкчылар үзләре сата. Чулман суыннан балыкны тоталар да, шундук ыслыйлар да. Гастрономик экстаз бу!

Хәер, дегустация белән ашыгырга кирәкми, сезне алда сыра оҗмахы көтә бит. Шәһәрдән бер чакрым ераклыктагы «Чистай» индустриаль паркында (Йолдыз бистәсенә таба барганда) «Белый Кремль» сыра музее урнашкан. Пыяла фасадлы бу бина турыдан-туры завод цехларына тоташкан.

Музейның беренче экспозициясе Чулман һәм Идел буйларында сыра кайнату тарихына багышланган. Әлеге традициягә инде 150 елдан артык икән. Кечкенә һөнәрчелек остаханәләреннән башланып, алар сәнәгать масштабларына кадәр үскән: 1867 елда Оскар Петцольд төзеткән беренче «Восточная Бавария» сыра кайнату заводыннан башлап безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Сүз уңаенда, музейда чын рыцарь бүлмәсе дә бар. Бирелә шул рәвешле Kaltenberg (Бавария) король замогы тарихы тәкъдим ителә. Анда Бавария короле гаиләсенең дөньяда бердәнбер гамәлдә булган сыра кайнату йорты эшли. Рыцарь турнирлары традициясенә гамәлдәге соңгы король онығының улы - принц Люитпольд Баварский заманында нигез салына. Чистайның белән нәрсә бәйле соң? Kaltenberg һәм KönigLudwig премиаль сәүдә маркалары сырасы! Ул «Белый Кремль» заводында җитештерелә. Эчемлек Бавария корольләре рецепты буенча Король Галиҗәнапләре сыра кайнатучысының турыдан-туры катнашында әзерләнә. Моны үз күзең белән күрергә мөмкин. Завод буенча экскурсия вакытында сезгә сыра кайнатуның башыннан азагына кадәр бөтен этапларын күрсәтәчәкләр. Соңыннан исә, әлбәттә инде, дегустациягә чакырачаклар.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан М7 буйлап, алга таба Шәле–Саескан Тавы трассасы буйлап, Алексеевское бистәсенә кадәр, аннары туп-туры Чистайга. Ара – 130 км
Җәмәгать транспортында да барып була: көн саен Казаннан Чистайга һәм кире рейс автобуслары йөри. Казанның Үзәк вокзалыннан китә торганнары да, алдан язылу буенча «Бәҗра» сәүдә үзәге янышннан китә торган хосусый машиналар да бар.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кунакханәдә. Бәясе – тәүлегенә ике кешегә 1800 сумнан башлап. Шәһәрдә туристлар өчен шулай ук кунак йортлары һәм хәтта ял базалары да бар.

ЧИСТАЙДА ТАГЫН НӘРСӘ КАРАРГА:
Җукәтау шәһәрлеген, әлбәттә! Археология комплексы Чистайдан ерак түгел, Чулманның сул ярында урнашкан. Сез анда Идел буе Болгарстанында X–XIV гасырларда көн күргән борынгы кала хәрабәләрен күрә алачаксыз. Шәһәрлек үзе 6 гектарга якын мәйдан били, анда берничә борынгы некрополь, шулай ук ныгытма калдыклары – туфрактан өелгән биек үрләр һәм алар арасындагы тирән чокырлар сакланып калган. Кайчандыр Җукәтау Чулман аръягының зур һөнәрчелек үзәге булган. Биредә балчык һәм пыяла савытлар җитештерелгән, металлургия һәм металл эшкәртү алга киткән. Казу эшләре вакытында табылган артефактларның кайберләрен Шәһәр тарихы музеенда күреп була.

НӘРСӘ САТЫП АЛЫРГА:
Легендар «Командирские» сәгатен, әлбәттә! Шулай ук җирле балыкчылардан ысланган балык һәм аның янына биредә җитештерелгән сыра сатып алырга була.

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Борис Пастернак музеенда алырга була: Чистай ш., Ленин ур., 81

ӘДӘБИ
ЧИСТАЙ

Чулман буендагы бу кечкенә шәһәрчек сугыш елларында илнең иң мөһим иҗат үзәгенә әверелә, анда ике йөздән артык язучы совет сугышчыларына көч биреп тора. Аларның Чистайда иҗат иткән әсәрләре совет әдәбиятының алтын фондына кергән.

Алар ничек көн күргән? Нинди авырлыклар кичергән һәм аларны ничек җиңә алган? Шул кырыс чорда нәрсәдән илһам алган? Чистай дәүләт музей-тыюлыгы тарафыннан әзерләнгән «Әдәби Чистай» туристлык маршрутында әнә шулар хакында белеп була. Тарихи шәһәр буйлап сәяхәт тылдагы якты иҗади тормыш сурәтләрен ачып, язучылар әләккән мохитне, алар кичергән фаҗигале вакыйгаларны да матурламыйча-бизәмичә күрсәтеп бирәчәк. Әлеге тиңсез экскурсия мизгелләренең берничәсен генә булса да тәкъдим итәбез.

СКАРЯТИН БАКЧАСЫ

Бу сукмаклар буйлап совет чорының әдәбият-сәнгать йолдызлары – язмыш җилләре Чистайга китергән бик күп күренекле затлар йөргән. 1941 елның 10 августында аларның халык белән тәүге очрашуы да менә шушында була. Бу истәлекле көнне сәхнәдә язучылардан Михаил Исаковский, Николай Асеев, Константин Тренев балкый... Конферансье ролендә драматург Николай Виноградов-Мамонт чыгыш ясый. Чистайда иҗат тормышының гөрләп үсү чоры әнә шулай башлана.

БОРИС ПАСТЕРНАК МЕМОРИАЛЬ МУЗЕЕ

Ленин урамы, 81 нче йорт. Икенче каттагы кечкенә генә бүлмәдә Нобель премиясе лауреаты Борис Пастернакның иҗат җәүһәрләре – «Ромео һәм Джульетта», «Антоний һәм Клеопатра»ның искиткеч тәрҗемәләре һәм, әлбәттә, үз әсәрләре туа. Чистайда

ул үз гомеренең иң төп хезмәте – «Доктор Живаго» романы өчен материал җыя. Ә эш арасында... эшләргә өлгерә. Бәдрәфләр чистарта, баржадан бүрәнә ташый... Һәм мондый авыр хезмәт бер дә кәефен төшерми аның. Шагыйрь үзе әйткәнчә, аны сугыш һәм Шекспир үзгәрткән. Мондагы диварлар шул хакта хатирәләрне кадерләп саклый.

ӘДӘБИ ФОНД ИНТЕРНАТЫ ЙОРТЫ

Алексей Баталов, Тимур Гайдар, Леонид Пастернак... Атаклы язучыларның эвакуацияләнгән балалары сугыш елларында нәкъ менә биредә, Колхозчы йортында сыенып урын таба. Барлыгы 150дән артык бала. Әлеге диварлар никадәр күп истәлекне хәтерли! Сабыйларның ничек тиз өлкәнәеп китүе, энилләренең иң кара, пычрак эштән дә тартынмавы турында хатирәләрне... Шулай ук фронтовик-язучылар белән очрашулар, «Язучылар – Сталинградка» хәйрия кичәсен әзерләү һәм хәтта Пастернакның «Кышкы төн» премьерасы хакында да сөйли ала алар.

ШӘҺӘР СОВЕТЫ БИНАСЫ

1942 елның 23 июнендә «Темп» кинотеатрында яшьләрнең фашистларга каршы митингы уза. Анда Николай Асеев үз шигырьләрен укый. Ә бераз соңрак, 19 июльдә, биредә Михаил Исаковскийга багышланган әдәби кичә уза. Аның иҗатына заманында бөтен Чистай гашыйк була. Кинотеатр 1900 елда төзелгән Сәүдә йорты бинасының бер янкормасын алып тора. Бинаның үзәк өлешендә шәһәр башкарма комитеты урнашкан була. Күпме әдипнең язмышы шушы бинада хәл ителгәндер! 1941 елның августында Марина Цветаева да шәһәрдә теркәлү өчен шушы бинада рөхсәт алган.

УКЫТУЧЫЛАР ЙОРТЫ

Бу чын иҗат үзәге була! Шигъри кичәләр, спектакльләр, концертлар һәм, әлбәттә инде, Совет Язучылары берлеге бүлекчәсе утырышлары. 1941 елның ноябрендә биредә Александр Фадеевның «Бөек Ватан сугышында совет язучылары» дигән тарихи чыгышы яңгырый. Монда ук, салкын бүлмәдә, керосин лампалары яктысында Пастернак үзенең «Ромео һәм Джульетта» тәрҗемәсен, ә Исаковский лирик шигырьләрен укый. Әйе, бу чып-чын премьералар урыны була, халкыбызның «Летели на фронт самолеты», «Огонек» кебек яраткан сугыш җырларының сүзләре дә беренче тапкыр шушы йортта дөнья күрә...

Экскурсиягә ничек заказ бирергә:
Шалтыратыгыз: 8-(84342)-5-17-01
Языгыз: gorodnakame2012@mail.ru
Килегез: Чистай ш., Карл Маркс ур., 31нче йорт.
Сайт: www.chisto-muzei.ru

Фотолар Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгыннан алынды. Реклама.

ИМИН ҺӘМ УҢАЙЛЫ

Клиент мәнфәгатенә өстенлек бирү, ышанычлылык һәм иминлек – республиканың транспорт хезмәтләре базарында «Буревестник» ҖЧҖ ширкәтенең унҗиде еллык эш дәверендә төп шартлар ул. Бүген Татарстанның алдынгы транспорт компанияләренең берсе булып, «Буревестник» хезмәт күрсәтү сыйфаты һәм пассажирлар ташу күләме рейтингларының беренче баскычларын били, ә аның алыштыргысыз җитәкчесе «Россия Федерациясенең атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булган.

Әбу уңыш юлы 2004 елда алары да инде кулланышта булган нибары өч автобустан башлана. Хәзер исә Казан предприятиесе автопаркында заказ белән пассажирлар йөртү өчен йөз илледән артык уңайлы автобус бар, ә аларның яше 5 елдан артмый. Автобус паркыннан тыш, предприятиенең микроавтобуслары, бизнес-класслы һәм иң югары класслы җиңел автомобильләре бар. Компания эшчәнлегенең төп юнәлеше – автомобиль транспорты белән шәһәрара, төбәкара һәм халыкара дәрәҗәдә пассажирлар ташу эшен оештыру һәм гамәлгә ашыру.

Бик зур юл үтелгән. Бүген «Буревестник» иң заманча технологик җиһазлар белән тәэмин ителгән куәтле җитештерү-техника базасына ия. Предприятиенең автопаркына үз ремонт цехларында гына хезмәт күрсәтелә, территориядә үзюу комплекслары һәм ике җитештерү цехы бар. Аларның берсендә калай эшләре, эретеп ябыштыру башкарыла, икенчесендә төзекләндерү-ремонт эшләре алып барыла.

Автобусны парктан чыгаруга әзерлек һәм юл кәгазен тутырудан башлап, аны саклау урынына кайтарып куюга кадәр эзлекле технологик чылбыр автоматлаштырылган идарә системасы белән көйләнә.

Транспорт тармагына «цифрлы технологияләр» ышанычлы адымнар белән килеп керде. Предприятие диспетчерларының, механикларның, эксплуатация һәм финанс хезмәтенең эше гомум бер программа нигезендә берләштерелгән. «Буревестник»ның һәр автобусы, микроавтобусы һәм автомобиле машина йөртүчеләрнең эш вакытын исәпкә алу системасы, видеотеркәгечләр, навигация системалары һәм салон видеокамералары белән җиһазландырылган.

Транспорт чарасына урнаштырылган заманча җиһазлар аның кайдалыгын онлайн режимда күзәтеп торырга мөмкинлек бирә. Болар барысы да – пассажирның иминлеге өчен. Нәкъ менә юл хәрәкәте иминлеге, җитәкче сүзләренчә, беренче урында тора. Бу хакта хәбәрдар булганга, клиентлар да компаниягә ышана. Шуңа күрә «Буревестник»ның заказлар портфелендә һәрвакыт иң җаваплы эшләр булган һәм алар дәвам итә. Әйтик, предприятие дөньякүләм масштабтагы спорт ярышларына хезмәт күрсәтү эшенә җәлеп ителгән. Алар арасында Казанда узган 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, Сочидагы кышкы Олимпия һәм Паралимпия уеннары, 2015 елгы Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2016 елда узган ФИФА Конфедерацияләр Кубогы жирәбәсе бар. 2017 елда «Буревестник» ҖЧҖ ФИФА Конфедерацияләр Кубогына, 2018 елда – Футбол буенча дөнья чемпионатына, 2019 елда – WorldSkills һөнәри осталык буенча дөнья чемпионатына хезмәт күрсәткән.

Хезмәткәрләр компаниядәге эш урыннарының кадерен белә. Биредә кадрлар алышынып тору күренеше юк диярлек, чөнки лаеклы хезмәт хакы гына түләнеп калмыйча, өстәмә яллар да бирелә, матди ярдәм дә күрсәтелә.

«Буревестник» ҖЧҖ республикадагы балалар йортларына, инвалидлар җәмгыятьләренә, дини оешмаларга ярдәм күрсәтә. Аз керемле гаиләләргә Санкт-Петербург, Мәскәү һәм башка шәһәрләргә бушлай экскурсия юлламалары бирелә. «Буревестник» ҖЧҖ җитәкчесе, Яңа Чишмә районының Рус Волчья Бистәсе авылында туган Вячеслав Улитин райондагы күп кенә чараларның иганәчесе булып тора.

Бүген хезмәттәшләре аны «Россия Федерациясенең атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем алу белән котлый:

– Хөрмәтле Вячеслав Михайлович! Мондый һөнәри уңышларга максатчан кеше генә ирешә ала. Һәм без киләчәктә сезнең алда яңа җиңүләр һәм проектлар булачагына ышанабыз. Сезгә сәламәтлек, эшегездә яңа уңышлар, тормыш энергиясе телибез. Һәрвакыт шундый игътибарлы, сизгер һәм актив булып калыгыз!

Фотолар «Буревестник» ҖЧҖ тарафыннан бирелде. Реклама

3

БАЛЫК БИСТӘСЕ: АСЫЛ БОЛАННАР ҺӘМ ЧУРТАН БУРГЕРЛАРЫ ТӨБӘГЕ

Балык Бистәсенә сәяхәт кылу – табигать кочагында тәмле һәм кызыклы ял, дигән сүз. Район үзәге очсыз-кырыйсыз Чулман елгасы ярында урнашкан, җирлектә табигый байлыклар мулдан, һәм биредә яшәүчеләр ул байлыкларны акыл белән, сакчыл файдаланып кына калмый, туктаусыз тулыландыра да әле. Балык Бистәсенең кунакчыл халкы һөнәрчелек гореф-гадәтләре белән бик теләп уртаклаша. Туристларны җәлеп итәрдәй кыйммәтләр районның гербында ук «яшерелгән»: зәңгәр төс әлеге төбәк өчен су ресурсларының никадәр әһәмиятле булуын ассызыклый. Гасырлар дәвамында Чулман Балык Бистәсе халкы тормышында бик мөһим роль уйнаган. Бүген җирле балыкчы артельләре 15ләп төр балык тота. Чулманга саф чишмә сулары да кушылганга, мондагы балыкларның тәме дә аерылып тора, диләр. Җирле осталар әзерләгән балык деликатесларыннан авыз итәргә теләүчеләр аларны бистәнең үзәгендә таба алачак – ресторанда яки балык «сувенирлары» кибетендә. Кармак салырга яратучылар исә, кунакханәдән чыгып, биш минут җәяүләп баруга, причалга төшеп җитә һәм бәхетен сынап карый ала! Гербта сурәтләнгән балык ятьмәләре – челтәр бәйләү һәм зәркән һөнәрләренә ишарә. Челтәр үрү һөнәренең асылына мастер-классларда төшенергә мөмкин. Саф һава сулыйм, дисәң, бистә янәшәсендәге урманның яшерен сукмакларына рәхим ит – файдалы үсемлек һәм җиләк җыеп, үзең белән дә алып китә аласың. Узган елдан бирле Балык Бистәсе районында тимгелле болан һәм мараллар белән дә якыннан хозурланырга була, Степановка авылы янәшәсендә, район үзәгеннән 45 чакрым ераклыкта «Кыргый ферма» экопаркы эшли.

Якын киләчәктә биредә джип-сафари маршрутлары да булдырырга уйлыйлар.

БЭМБИ КАРДӘШЛӘРЕ

«Кыргый ферма»ны гамәлгә куючы Альберт Камалиев берничә ел элек Карловы Вары (Чехия) янында асыл боланнарны ничек үрчетүләрен һәм нинди шартларда асрауларын күреп кайта. Татарстанда да шундый питомник булдыру нияте туа. «Кыргый ферма»ның максатларыннан берсе – биологик күптөрлелекне тәэмин итү. Асыл боланнарның безнең территориядә сакланып калган бердәнбер вәкиле – кыр кәҗәсе. Ә тимгелле боланнарга (икенче төрле аларны чәчәк болан дип тә атыйлар) менә-менә юкка чыгу куркынычы яный: табигатьтә аларның баш исәбе 3 меңнән дә кимрәк исәпләнә. Ярымкыргый шартларда мараллар һәм тимгелле боланнар үрчетү проектына Альберт Камалиев 2014 елда керешә. Ул чакта фермага Алтайдан 17 тимгелле болан һәм 24 марал алып кайталар. Өч елдан алар үрчи башлый. Тулысынча ияләшкән хайваннарны иреккә җибәрәләр. Инде шундый берничә «чыгарылыш» булган. Хәзерге вакытта фермада 200ләп хайван яши. Тимгелле боланнар кешеләрне ярата, кызыксынучан, алар аерым вольерларда көн итә. Балалар гына түгел, хәтта олылар да сәгатьләр буе җирәнкәйләрне сыйпарга әзер. «Кыргый ферма»ның инфраструктурасы киңәйтелә, камилләштерелә. Якын киләчәктә биредә джип-сафари маршрутлары да булдырырга уйлыйлар. Тагын бер зур максат – кыргый хайваннарны яклый торган хәйрия фонды оештыру.

Чуртан кәтлите һәм соус кына кунаклар мәхәббәтен яулый алмаса, Каргановлар икенче бер экзотик ризык тәкъдим итә – балык кыстырылган чебурек.

Тәмлетамакларга

ЧУРТАН КӘТЛИТЕ ҺӘМ ТЫЛСЫМЛЫ СОУС

Җирле балык бургеры барлыкка килүнең аш-су җәүһәрләренә хас тарихы бар. Аны ирле-хатынлы Карагановлар уйлап тапкан. Балыкчылар династиясе дәвамчыларының балык тоту предприятиесендә бүген 25 кеше хезмәт куя. Мамадыштан Саескан Тавына кадәрге акваториядә елына 200 тонна балык тоталар. Бер өлешен үзләренең предприятиесендә үк эшкәртәләр.

Җирле «Фасоль» кибетендә сатыла торган салкын һәм кайнар ысул белән ысланган балык – Балык Бистәсенең үзенчәлеге, йөзек кашы. Сыла, корбан балыгының филесын, стейкларын кумәртәләп тә алалар. Чи балыкның бер өлеше Казан, Самара, Ульяновск, Ростов-на-Дону шәһәрләренә җибәрелә. 2000 нче еллар башында Карагановлар Балык Бистәсендә үз кафеларын ачкан. Менюда төп урын, әлбәттә инде, балыкка бирелгән. Бары тик җирле балыкка. Чулманда хәзерге вакытта корбан, алабуга, кәрәкә, җәен, берш (сыланың бер төре), ачкүз кисәүбаш (ротан) балыкларын тоталар.

Әмма балыкны традицион рәвештә әзерләп бирәүне дә шаккаттырып булмый, шуңа күрә кафе өчен махсус меню уйлап табалар. «Чуртан» сүзен ишетүгә башка иң беренче нинди уй килә – кәтлит! Телне йотарлык! Яңа тотылган балыктан, тәмле... Балык бургерының нигезен энә шул чуртан кәтлите тәшкил итә. Әмма күпне күргән сәяхәтчеләрне дә таң калдырырга кирәк бит! Шуңа охшаш ризык, мәсәлән, Төркиядә бар. Шуңа да балыкның тәмен тагын да яхшырак ача торган соус уйлап табыла. Аның рецепты бер көндә генә барлыкка килмәгән. Карагановлар аны бар гаиләләре белән уйлый. Соус алты ингредиенттан гыйбарәт, үз кунакларына балык бургерының авторы бу рецептны зур сер буларак кына ача. Соуска кирәкле бар әйбер дә Карагановларның үз бакчасында үсә. Әмма бу соус – балыкка мәдхия ул... Чуртан кәтлите һәм соус кына кунаклар мәхәббәтен яулый алмаса, Карагановлар икенче бер экзотик ризык тәкъдим итә – балык кыстырылган чебурек. Халык телендә анысын балык-чебурек дип атап өлгергәннәр инде.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Машинада. М-7 яки Р-239 трассалары буенча Балык Бистәсенә кадәр (90 чакрымнан бераз гына артык) 1,5 сәгатьтә барып җитәргә мөмкин.
Казан–Балык Бистәсе автобусында. Казанның Үзәк автовокзалыннан китә. 2 сәгать бара. Билет бәясе – 210 сум.*

«КЫРГЫЙ ФЕРМА»ГА НИЧЕК БАРЫРГА:
Балык Бистәсеннән шәхси автомобильдә яки такси белән. Ферма Степановка авылы янында урнашкан. 45 чакрым юлга якынча 50 минут вакыт китә. Билет бәясе – 50 дән 500 сумга кадәр. 3 яшькә кадәр балалар бушлай кертелә. Фермада иртәнге 9дан кичке 20:00 сәгатькә кадәр йөрергә була.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кунакханәләрдә. Ике кешелек бүлмә – 1800 –2600 сум.*

КАЙДА СЫЙЛАНЫРГА:
Җирле кулинария шедеврына әверелгән тәмле балык бургерыннан кафеда авыз итәргә була. Балык бургерының бәясе – 250 сум. Кафеда уртача чек – 500 сумнан 1200 сумга кадәр*.

СУВЕНИР ҺӘМ КҮЧТӘНӘЧЛӘР:
Төрлечә зәерләнгән балык, магнитлар, кулдан ясалган сабын һәм башка вак-төяк сувенирлар, Олы Елга авылыннан фермерлар продукциясе, хуш исле икмәк.

** Бәяләр 2021 елның май аена.*

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны «Аяз» кунакханәсендә алырга була: Балык Бистәсе авылы, Ленин ур., 15.

4

МАМАДЫШ:
БЕЗНЕҢ ПАРИЖ

Мамадыш – ачык һавадагы чын музей ул, аның урамнарыннан барганда, таң калырлык нәрсәләр бик күп очрый. Мәсәлән, Лев Николаевич Толстойга куелган һәйкәлгә сокланмый мөмкин түгел – анда бөек язучының дусты, тарихчы Дмитрий Голохвастовка язган хатыннан алынган мондый цитата уелган: «Сез ышанмассыз да, әмма мин, Венеция, Рим, Неапольдә яшәгәнче, Мамадышны сайлар идем...» диелгән. Ә Мамадыш чыннан да бик шәп – тикмәгә генә йөз меңнән азрак халык яши торган шәһәрләр арасында ул Россиядә иң яхшы дип табылмаган бит!

Бу торак пунктка 600 елдан артыграк. Баштарак ул Казан ханлыгы шәһәрләреннән берсе, аннары – ныгытма-гарнизон, соңрак исә иң шәп сәүдәгәрлек традицияләрендәге өяз шәһәрчеге булган. Шунлыктан биредә заманчалык тарихның үзе, кайберләре риваять-мифлар белән катышкан, алар иронияcе белән теләсә кайсы туристны гаҗәпкә калдырырлык.

260 мең гектар җир, 100 елга, 300 инеш, 42 мең кеше – Мамадыш районының статистикасы менә шундыйрак. Бу – Татарстанда иң зур район, аның мәйданы Европадагы кечерәк бер дәүләтнеке кадәр. Мәсәлән, Люксембургныкы хәтле. Хәер, башка, туристлар өчен кызыклырак статистика да бар: районда өч театр, дүрт музей, илле дүрт китапханә эшли. Биредә мәдәни мирасның унтугыз объектын – борынгы шәһәрлекләр, кабер ташлары, тарихи биналарны күреп була. Мамадышның үзендә исә һәйкәл, монумент, скульптура, инсталляцияләр бихисап: рәсми булмаган статистика буенча – һәр утыз метр саен!

Шәрык йолдызнамәсендәге унике җәнлек сыны, тәпиләренә музыка уен кораллары тоттырып, агачтан юнып ясалган!



1918 елда Пузанка тавы кызылармиячеләр өчен туганнар каберлегенә әйләнгән.

Истәлекле урыннар

НОКРАТ ЯР БУЕ

Искиткеч күркәм Нократ яр буе – шәһәрнең чын бизәге. Анда сәйран кылу үзе бер ләззәт. Музыкаль фонтан берничә дистә композиция башкара, ә аннан ерак түгел «җәнлекләр оркестры» үз шлягерын уйнарга әзерләнә. Шәрык йолдызнамәсендәге унике җәнлек сыны, тәпиләренә музыка уен кораллары тоттырып, агачтан юнып ясалган! Янәшәдә исә борынгы каравелла рәвешендәге кафе һәм чын замоктай ресторан урнашкан.

ПУЗАНКА ТАВЫ

Әлеге тау башыннан шәһәргә һәм Нократ елгасына гаҗәеп манзара ачыла. Әмма бу гүзәл урынның ачы тарихы бар. 1918 елда Пузанка тавы кызылармиячеләр өчен туганнар каберлегенә әйләнгән. Көчләр тигезсез була. Отряд ачык тау битеннән шәһәргә таба юнәлә. Ак гвардия солдатлары пулемет һәм туплардан ут ача. Йөз кеше һәлак була. Шәһәр халкы сугышчыларны шул төндә үк җирли. Туганнар каберлегенә йолдызлы һәйкәл куелган.

ПАРИЖГА – МАМАДЫШ АША!

Татарстандагы бу шаярту һәркемгә мәгълүм. Әмма һәр мәзәктә хакыйкать тә бар, диләр бит! Борынгы хикәяттән күренгәнчә, Франция башкаласының иң шәп рестораннарына баканы Мамадыштан китерткәннәр, имеш! Бу әле революциягә кадәр үк булган: Мамадышның бер елгыр эшкуары симез бакылдыкларны Парижга ташуны җайга салган, иң шәп пешекчеләр исә аларны бик теләп алган, диләр.

Башка легенда да бар. Бусы бакалар турында түгел, бәлки гөмбә хакында. Җирле халык гөмбә ашамаган, әмма шәһәрдән ерак түгел туктарга мәҗбүр булган пароход пассажирларының урмандагы әлеге байлыкны күреп исе киткән. Арадан бер турист исә бик эшлекле булып чыккан: шампиньон аланнарының муллыгын объектив бәяләп, Мамадышта гөмбәдән консерва җитештерүне җайга салган. Шул рәвешле Мамадыш шампиньоннары Париждагы бер күргәзмәгә барып эләккән һәм нәзакәтле тәме өчен хәтта алтын медальгә дә лаек булган.

Әлеге мәгълүматны хәзергә кадәр кире кагучы юк – парижлылар да, мамадышлылар да. Җирле эшкуарлар француз акцентлы әлеге гастрономик тарихны бренд дәрәҗәсенә күтәргән һәм моннан шактый уңышлы файдалана да. Дөрес, туристлык мәнфәгатьләрендә. Үзегез уйлап карагыз: Эйфель манарасы янында селфи ясау – күп сәяхәтченең хыялы, ул исә Татарстандагы кечкенә генә Мамадышта тормышка ашырырга мөмкин. Парижның төп һәйкәленең тугыз метрлы күчермәсе Мамадыш үзәгенә урнаштырылган. Шәһәр яр буенда исә оригиналга кадәр ераклык теркәлгән күрсәткеч тора. Мамадышның үз «Париж»ы – кечкенә генә сәүдә үзәге дә бар. Әлбәттә, ул Франция бутикларының хәтта күчермәсенә дә тартмый, шулай булса да, бу «Париж»га Мамадыш аша бик җиңел эләгеп була.

PRESSA

Тәмлетамакларга

ТАТАР ПАРМЕЗАНЫ?

Татар пармезаны, дисезме? Әйе-әйе, нәкъ шулай! «EXPO-2015» халыкара күргәзмәсендә Милан экспертлары «Татар deluxe» сырына мактый-мактый шундый кушамат таккан. Итальян прототибын Мамадышта җитештерәләр, бу шәһәр – чын сыр төбәге бит! Егерме төрдән артык югары сыйфатлы сыр – мамадышлыларның горурлыгы һәм импортны алыштыру процессы нәтиҗәсе. Хәер, сыр ясаучылар «Делюкс» рецептын әлеге күңелсез вакыйгалар башланганчы ук уйлап тапкан идек, дип ышандырмакчы. Нәкъ менә ул Мамадыш сырының сыйфатын күтәрүгә этәргеч булган да. Бер елдан соң бирeдә инде немец аналоглары линейкасы да пәйда булган – җирле «Маасдам», «Тильзитер», «Эдам» Россиядә иң тәмлеләрдән, диләр!

Биредә сыйфат йөз кызартырлык түгел: Мамадыш сырының 1 килограммын ясау өчен, кимендә, 10 литр сөт китә. Аның чисталыгын исә лабораториядә тикшерәләр һәм антибиотиклы продукцияне кабул итмиләр. Барысы да табигый, чын – бернинди пальма мае да кулланылмый!

Моңа ничек ирешкәннәр соң? Сере бик гади: сыр Италия җиһазларында җитештерелә, предприятиене эшләтеп җибәрү белән дә итальяннар шөгыльләнгән. Алар мамадышлыларны сыр ясау нечкәлекләренә өйрәткән. Сыр оеткысын Даниядән кайтартканнар. Уникаль рецептура Голландия белгечләре белән берлектә эшләнгән. Мамадыш сырының бәләкәй генә кисәгенә әнә нинди зур халыклар дуслыгы сыйган!

Биредә сыйфат йөз кызартырлык түгел: Мамадыш сырының 1 килограммын ясау өчен, кимендә, 10 литр сөт китә. Аның чисталыгын исә лабораториядә тикшерәләр һәм антибиотиклы продукцияне кабул итмиләр. Барысы да табигый, чын – бернинди пальма мае да кулланылмый!

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан М7 трассасы буйлап Мамадыш борылышына кадәр. Ара – 164 км.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кунакханәдә, Мамадышта алар берничә. Бәясе – ике кешегә (иртәнге аш белән) тәүлегенә 1400 сумнан башлана. Бер тәүлеге 1000 сумга фатирга керергә дә мөмкин.

НӘРСӘ КАРАРГА:
17 июльдә Мамадыш районы Җөри авылындагы Тырлау аланында Питрау үткәрелә. Керәшеннәр аеруча хөрмәтләгән «Чәчәк бәйрәме» шулай атала. Ул җәй бетүне, димәк, печән өсте башлануны белдерә. Совет чорында Питрау тыелган була һәм Татарстанның Мамадыш җирендә күптән түгел генә яңадан торгызыла. Әлеге уникаль йола традицияләре христиан элементларын да, борынгы төрки элементларны да берләштерә. Күңелле әйлән-бәйлән, үзенчәлекле җырулар, спорт ярышлары – берничә мең кеше җыела торган гаять зур чараның бер өлеше генә.

НӘРСӘ АЛЫП КИТӘРГӘ:
Җирле заводта җитештерелгән төрле сортлы сырларны, балачак тәмен саклаган Мамадыш лимонадын, шулай ук Кирмәндәге Изге чишмәләрнең сихәтле суын.

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Мамадышның Төбәкне өйрәнү музеенда алырга була: Мамадыш ш., Совет ур., 12 Б.

5

БАЙЛАР САБАСЫ: КҮҢЕЛЛЕ ҺӘМ БАЙ

Казаннан сәгать ярымлык ераклыкта урнашкан гаҗәеп урынны асылташлар тулы сандык белән генә чагыштырып буладыр. Бу очракта сүз туристик җәүһәрләр турында бара. «Миңгәр Тауэр» манарасы үзе генә дә ни тора! Казандагы Сөембикә манарасының игезәге Миңгәр авылына кергәндә үк каршы ала. Манараның игезәге аның кечерәйтелгән күчермәсе түгел – биеклеге буенча башкаладагыдан сигез метрга озынрак та әле. Өстәвенә, ул буш тормый, биредә кунакханә-ресторан комплексы урнашкан. Уңайлылык дәрәҗәсе буенча шәһәрдәгедән һич ким түгел!

Гомумән, сабалыларның бөтен зур, төплегә, «иң-иңгә» мәхәббәте һәр адымда диярлек сизелә. Биредә иң затлы Сабан туе уздырыла, үзләренең бик зур дендрарие бар, илдә иң зур кәҗә фермасы эшли һәм хәтта урманы да республикада иң эре яшел массив санала. Сабаның истәлекле урыннары чыннан да үзенең зурлыгы белән шаккатыра. Әйтик, биредәге кунакчыллык символы – ике метр биеклектәге самовардан саф чишмә суыннан кайнатылган чәй эчәргә мөмкин. Саба елгасының төзекләндерелгән яры буйлап хозурланып йөргәндә гаять зур агач арт-объектка – моллюск кабырчыгына тап булырсыз. Ә аның эчендә бау ишеп ясалган тулы бер аттракцион!

Актив һәм хәтта ки экстремаль ял яратучылар өчен Байлар Сабасына сәяхәт тәэсирләргә бай булачак. Велосипедта, махсус трасса буенча скейтбордта һәм роллерда йөрү – мондагы мөмкинлекләрнең бары тик аз өлеше генә. Биредә мылтыктан атарга, атта йөрергә, бау паркында һәм скалодромда күңел ачарга, «Городки», пейнтбол, гольф, һава хоккее уйнарга һәм хәтта картингта узышырга була!

Истәлекле урыннар

КЫҢГЫРАУЛАР МУЗЕЕ

Балачакны хәтерләткән бәхетле мизгел! Әлеге музейда шундый хисләргә бирелергә буладыр. Хәер, бу коллекция чәчләренә чал кунган кунакны да шаккатыра ала, чөнки анда 239 кыңгырау, шөлдерчек, гөмбер, хәтта ки чиркәү чаңы саклана. Аларның һәркайсының – кабатланмас үз тавышы! Тавышларны үзеңә тыңларга була, чөнки мондагы экспонатларны тотып карау мөмкин генә түгел, шулай эшләргә кирәк тә. Хәтта иң зурысын һәм борынгысын – XIX гасырда ук коелганын да!

ДЕНДРАРИЙ БАКЧАСЫ

11 гектар мәйданны билгән бакчада агач, куак, яшелчә культураларының һәм чәчәкләрнең биш йөздән артык төрен күрергә мөмкин. Шул исәптән – Европа, Азия, Америкада үсә торган иң сирәк төрләрен дә. Әлеге үзенчәлекле дендрарий бакчасына экскурсиягә туристлар алдан ук язылып куя икән. Җирле оранжереядә сезне тагын да кызыклырак дөнья көтә – анда тропикларга гына хас үсемлекләр үсә. Әгәр уңай туры килсә, мәсәлән, ананас һәм банан өлгерүен дә үз күзегез белән күрергә мөмкин.

Коллекциядә 239 кыңгырау, шөлдерчек, гөмбер, хәтта ки чиркәү чаңы саклана.



1990 нчы елларда, мәчетне реставрацияләп, дин тотучыларга кире кайтаралар.

ӨТЕРНӘС ШӘҺӘРЛЕГЕ

Казу эшләре шуны раслый: биредә ныгытма булган. Аның яшәү дәвере Казан ханлыгының соңгы елларына туры килә, ди тарихчылар. Мишә-Тамак ныгытмасы телгә алынган елъязмалар эзләнү эшләре өчен этәргеч була. Кечерәк кенә шәһәрлекне озын чокырлар, туфрак өемнәре саклаган. Археологлар ныгытманың чыннан да булуын раслаган башка артефактлар да таба: борынгы корал, хатын-кыз бизәну әйберләре, тәңкәләр, хезмәт кораллары, йорт кирәк-яраклары. Әлеге табылдыкларның кайберләре Саба төбәкне өйрәнү музеенда экспонат буларак саклана.

БЕРЕНЧЕ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

Әлеге ике катлы таш гыйбадәтханә – дини архитектура ядкәре. Ул 1841 елда салына. Мәчет төзелешенә акчаны атаклы Казан сәүдәгәрләре һәм хәйриячеләре нәселе вәкиле Абдулкәрим Юнысов бирә. Совет хакимияте урнашканчыга кадәр мәчетне күренекле дин әһелләре җитәкли. Әмма 1930 елда мәчет үз эшчәнлеген туктатырга мәҗбүр була, аның манарасы киселә, бинага кинотеатр һәм китапханә урнаша. 1990 нчы елларда, мәчетне реставрацияләп, дин тотучыларга кире кайтаралар.

МӘККӘ БЕЛӘН ЭЛЕМТӘДӘ

Югары технологияләр белән борынгылыкның бердәмлеге – Саба районының үзенчәлеге. Шуңа күрә мәдрәсә тарихына багышланган илдә бердәнбер интерактив музей биредә – Сатыш авылында урнашкан. Ул 1893 елда салынган бинада урын алган. Кайчандыр монда Европадагы иң зур авыл мәдрәсәләренең берсе эшләгән. Анда өч йөздән артык шәкерт укыган. Хакимияткә советлар килү белән, мәдрәсә үз эшчәнлеген туктаткан. Ач-ялангач, салкын сугыш елларында бинаның икенче катын утынга тоталар. Беренче катта озак еллар дәвамында авыл мәктәбе эшли. Аннан соң бина буш тора. 2015 елда бинаны торгызырга, аңа җан өрергә, тарихи хәтерне яңартырга карар кылалар.

Бүген музей экспозициясенең уртасында йортның элек ничек булганлыгын чагылдырган макетны күрергә, аның тәрәзәләренә күз салырга, уку сыйныфларын һәм торак бүлмәләрне карарга була. Бер сүз белән әйткәндә, бүгенгедән XIX гасырга кайтырга мөмкин. Интерактив панельләр һәм заманча җиһазлар ул вакыт мохитенә тагын да тирәнрәк чумарга ярдәм итә. Тарихи мәгълүмат дүрт телдә – русча, татарча, инглизчә һәм гарәпчә бирелә. Ләкин бу гына да түгел әле! Проекторлар музейны күп үлчәмле дөньяга әвереләдерә: бер залда Мәккәдән турыдан-туры трансляция бара, икенчесендә Саба районының барлык мәчетләре буенча виртуаль тур оештырырга мөмкин.

Әлбәттә, бу технологик музейда реаль экспонатлар белән дә танышырга була – мәдрәсә тормышын һәм шәкертләрнең көнкүрешен чагылдырган чын предметлар да бар. Мәсәлән, имам таягы, борынгы китаплар, шәкерт урындыгы, бинаны реставрацияләгәндә чормада табылган иясе билгесез букча һәм бөтиләр.

Интерактив панельләр һәм заманча җиһазлар ул вакыт мохитенә тагын да тирәнрәк чумарга ярдәм итә. Тарихи мәгълүмат дүрт телдә – русча, татарча, инглизчә һәм гарәпчә бирелә.

Каз маенда холестерин юк диярлек, ә ите аксымга һәм файдалы микроэлементларга бай. Бигрәк тә каз, дөрес итеп, экологик чиста урында үстерелсә.

Тәмлетамакларга

МЕНӘ СИҢА КАЗ! КАКЛАНГАН!

Парм ветчинасы, французларның суган ашы, испан хамоны... Һәр халыкның үзенә генә хас ризыгы бар. Каклаган каз инде күптәннән Татарстанның гастрономик брендына әверелде.

Дөресен генә әйткәндә, аны һәр татар авылында диярлек татып карарга була, әмма Сабада, мөгаен, каз үзе түгел, аны әзерләүчеләр үзенчәлекледер. Республикага җитди делегацияләр килгәндә, табын әзерләргә юкка гына Саба уңганнарын чакырмыйлардыр. Ил Президентын да бер генә мәртәбә үзләре каклаган каз белән сыйламадылар, дип тә сөйлиләр.

Затлы кунакларны сыйлый торган каклаган каз рецепты сабалыларда борынгыдан сакланып калган. Ул беркайда да язылмаган-теркәлмәгән, әмма каклау тәртибе буыннан буынга тапшырылып килгән. Сабача тәмле итеп ясар өчен, чистартылган казны, тоз белән ышкып, ярты елга ашлык эченә тыгып куялар, дип сөйлиләр. Ә аннан соң тозын сыпырып төшереп, тагын ярты елга үтәли җил уйный торган урынга элеп куялар. Мондый казның төсе куе кызыл, хәтта ки кызыл якут төсенә керә, ә тәме – тозлы каклаган. Сүз уңаеннан, каз ите тәмле генә түгел, файдалы да. Һәркемгә таныш факт: каз маенда холестерин юк диярлек, ә ите аксымга һәм файдалы микроэлементларга бай. Бигрәк тә каз, дөрес итеп, экологик чиста урында үстерелсә. Ә Саба районы – искиткеч табигать дөньясы.

Озын сүзнең кыскасы, сез хәзер әлеге ризыкны ни өчен татып карарга кирәклеген аңлыйсыз. Һәм һичшиксез – Сабада! Сүз уңаеннан, каклаган каз Татарстанда һәрвакыт затлы күчтәнәч саналган. Гореф-гадәтләр буенча, мондый бүләкне өйләнешүче яшь парларга да бүләк итәләр. Кияү кешегә – казның башын, кәләшкә – муенын. Күрәсең, «Ир – баш, хатын – муен, муен кай якка борылса, баш шул якка карый» дигән гыйбарә дә шуннан киләдер.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан Мамадыш тракты буенча, Ленино-Кокушкино аша. Байлар Сабасына кадәр ара – 100 км.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Күңел ачу-кунакханә комплексында, отельдә, яр йортында, коттеджда. Бәяләр ике кешегә тәүлегенә 1200 сумнан башлана.

КАТНАШЫРГА КИРӘК БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР:
Әлбәттә, Сабан туе! Байлар Сабасында Сабан туе бигрәк тә зурлап үткәрелә, дип сөйлиләр Татарстанда. Һәрхәлдә, аның даны еракларга таралган, ул инде күп еллар буе тынмый. Рәсми булмаган чыганакларга караганда, бу көнне Миңгәр авылында 100 меңгә кадәр кеше җыела. Ләкин кешенең күплегеннән, чиратлардан куркырга кирәкми – бәйрәмне оештыру аерым мактауга лаек. Шул ук вакытта берьюлы берничә мәйданда уздырыла торган программаның колачы кебек үк: традицион милли уен – көрәштән алып, мотофристайл-шоуга кадәр. Саба Сабан туе – ул әле татар милли аш-сулары белән танышу мөмкинлеге дә, биредә ул бигрәк тә киң төрдә тәкъдим ителә.

БАЙЛАР САБАСЫННАН НӘРСӘ АЛЫП КАЙТЫРГА:
Саба кырларыннан җыелган үләннәрдән ясалган хуш исле фиточәй, уникаль бизәкле агач һәм талчыбыктан үрелгән эшләнмәләр, җирле фермерлар тарафыннан җитештерелгән ысланган хәләл ризыклар.

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Сатыш авылында Музей-мәдрәсәдә алырга була: Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17 А.

PRESSA

6

КАМА ТАМАГЫ: КҮККӘ ТОТАШКАН ДИҢГЕЗ

Кама Тамагы: Татарстандагы Жигули таулары, Идел буе Кырымы һәм Каппадокия бер урынга тупланган җир... Атаклы балык тоту урыннары, штольнялар, мәгарәләр һәм таулар... Ә иң мөһиме – очсыз-кырыйсыз искиткеч пейзаж: биредә Россиянең Европа өлешендәге иң мул сулы ике елга – Чулман һәм Идел бергә кушыла. Үзеңне күккә тоташкан чын диңгез ярында дип хис итәсең! Биредә Куйбышев сусаклагычы төньяктан көньякка 43 чакрымга сузыла. Табигате белән хозурланыр өчен барырга кирәк сер тулы Кама Тамагына. Биредә бер-ике генә көн булса да ял итү һәркемгә озак вакытка җитәрлек көч-куәт өстәячәк.

Ике зур елга ярына салынган шәһәр тибындагы бистә – Кама Тамагы район үзәге кайчандыр Богородское дип аталган. Ул Казаннан 100 чакрымга көньяктарак урнашкан. Биредә мактанырлык истәлекле урыннар шактый. Данлыклы төбәкне өйрәнү музеенда сезгә районның табигате һәм сәнәгате турында, Максим Горький белән бәйле урыннар хакында һәм тәүге космонавт Юрий Гагарин ял иткән урыннар турында тәфсилләп сөйләячәкләр. Янәшәдәге агач бүрәнәдән буралган йортта татар драматургы һәм җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин музее урнашкан, анда язучының шәхси әйберләре, кулъязмалары һәм театр реквизиты белән танышырга мөмкин. Ландшафт тыюлыгында исә Лобач тавыннан Идел белән Каманың кушылу манзарасына карап хозурланырга була. Бу – районның иң биек ноктасы һәм символы. Илья Репин үзенең атаклы «Бурлаклар Иделдә» картинасының эскизларын нәкъ менә Лобач тирәсендә ясаган, диләр. Кама Тамагы бистәсеннән нибары алты чакрым ераклыкта, гипс мәгъдәнлеге территориясендә, Татарстанның дәүләт тарафыннан саклана торган ядкәре – Юрьев мәгарәсе урнашкан. Һәвәскәр спелеологларны ул һичшиксез кызыксындырмый калмастыр. Кама Тамагындагы балык тоту оҗмахын үз иткән ярты миллион балыкчы сафына да кушылырга була – июльнең икенче якшәмбесендә, Балыкчылар көнендә, биредә ел саен «Идел – Кама» яки уха фестивале уздырыла...

Юрьев мәгарәсенең тар лабиринтларына махсус кием-салымнан, фонарь тотып һәм бары тик юл күрсәтүче белән төшәргә киңәш ителә.

Истәлекле урыннар

ШТОЛЬНЯЛАР

Текә таш ярда – гипс мәгъдәнлегенең гигант штольнялары. Ап-ак кыялар, зәп-зәңгәр су, искиткеч манзара һәм ташландык штольняларның гигант лабиринты иң тәҗрибәле, күпне күргән туристларны да битараф калдырмаячак. Таулар эчендә тулы бер «ныгытма» урнашкан, аның «тәрәзәләреннән» иксез-чиксез «диңгез» белән хозурланырга була.

ЮРЬЕВ МӘГАРӘСЕ

Урта Идел буенда иң зур табигый Юрьев мәгарәсе 1953 елда ачылган. Шул вакыттан бирле Татарстан диггерлары экспедицияләре җир астында һаман яңа юллар таба: Бабуиннар залы, Маймыл читлеге, тар Китапханә, Лифт, Профессор йорты, Орган торбалары... Юрьев мәгарәсенең тар лабиринтларына махсус кием-салымнан, фонарь тотып һәм бары тик юл күрсәтүче белән төшәргә киңәш ителә.



ЙӨЗЕМ БАКЧАЛАРЫ

Кама Тамагыннан Уразлыга барганда яшь фермер Айрат Ялалетдиновның юл өстендәге йөзем бакчаларын күрми үтү мөмкин түгел. Әлеге гаять зур йөзем аланы турында хәзер районда гына түгел, бөтен республикада мәгълүм. Кибеттә дә, базарда да табып булмый торган әлеге хуш исле тәмле көньяк җимешен алырга дип, бүген яшь фермер янына бөтен Татарстаннан киләләр. Бакчадагы үзегезгә охшаган теләсә кайсы тәлгәшкә күрсәтәсез дә, шундук кисеп тә бирәләр.

Риваять

ИДЕЛ ҺӘМ ЧУЛМАН КУШЫЛГАН УРЫН

Борын-борын заманда бу җирләрдә Обач хан яшәгән, ди. Аның ике кызы булган: Идел һәм Чулман. Бервакыт алар бәхәсләшкән: кайсы сөйкемлерәк, гүзәлрәк, зирәгрәк... Бу турыда белеп алган әтиләре аларны ярыштырырга булган. Һәм шуннан башланган – кызлар берберсеннән уздырырга тырышып хәлдән тайган. Обачның мондый битарафлыгы бөек ханга ошамаган: «Син шундый каты күңелле икәнсең, кызларыңның ярышуын тыныч кына күзәтәсең икән, димәк, синең йөрәгең таш, димәк, бүгеннән син гасырлар буе моны күзәтәчәк кыя булачаксың. Кызларыңны исә, һәрвакыт бәхәсләшсеннәр һәм бер-берсе белән гел сөйләшеп-чөлтерәшеп торсыннар өчен, елгаларга әйләндерәм», – дигән.

Ә бит кайбер географлар, гидрологлар һәм төбәкне өйрәнүчеләр Каспий диңгезенә нәкъ менә Чулман коя, дип саный. Чулман һәм Идел – мәңгелек бәхәстә. Ике елга да үзенчә күркәм, чылтыравык, куәтле. Бергә кушылып, Кама Тамагында шундый гүзәллек тудыралар икән, кайсының кая койганы мөһиммени аның!

Тәмлетамакларга

ЮРИЙ ГАГАРИН ӨЧЕН УХА

1967 ел җәенең эссе көннәреннән берсен пешекче **Рита Мөхәммәдиева** беркайчан да онытмаячак. Ул көнне аңа Юрий Гагаринның үзе өчен ризык әзерләү бәхете елмая. Тәүге космонавт Антоновка чокырлары ярына... су чаңгысында килә.

Кама Тамагы халкы Гагаринны һәм аны озатып йөрүче түрәләрне мул табын корып каршы ала. Беренче аш – чөгә, сыла һәм алабуга балыкларыннан уха. Ысланган корбан, чөгә балыклары. Кама Тамагында балык – төп деликатес, биредә аны бик күп төрле әзерлиләр. Әлбәттә инде, табында әле тагын өчпочмак, тутырган тавык, камырга төреп пешерелгән каз да була. Барысын да үзләре ыслый, кыздыра, пешерә...

Космик кунак өчен уханы кәстрүлдә түгел, сигез литрлы чиләктә пешерәләр! Яртысын ашыйлар, яртысын исә пешекчеләр кунакларга юлга биреп җибәрә:

– Сыйландылар. «Бик-бик тәмле» булды дип мактадылар, рәхмәт укыдылар. Калган ярты чиләк уханы бирдек, юлда ашап бетерерсез әле дип, катерда дүртәү иде алар. Ә Юрий гаҗәпләнеп сорады әле: «Чиләге дә безгәме?» – ди. Тагын: «Рәхмәт-рәхмәт!» – диде. Бик әдәпле, ихтирамлы кеше иде, – дип искә ала Рита Лотфулла кызы.

Уханы кайда иң дөрес пешергәннәре турында бәхәсләшү мәгънәсез – һәркемнең үз рецепты. Ихтимал, Гагарин өчен Кама Тамагында әзерләнгән уханың төп сере елгадан яңа гына тотылган балыкта булгандыр. Билгеле инде, сыйланганда әйбәт компаниядә булу мөһим, ризыкка бөтен күңелен салып пешергән оста пешекчене дә онытырга ярамый.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Татарстан башкаласыннан Кама Тамагына кадәр автомобильдә 1,5–2 сәгатьтә барып җитеп була. Башта М-7 трассасыннан Иннополис ягына барырга, аннары сулга, Р-241 юлына борылырга кирәк.
Казанның Воровский урамында урнашкан «Төньяк вокзал»дан Кама Тамагына кадәр 529 нчы автобус йөри.
Кама Тамагына су юлы белән дә барып була. Җәен Казан елга портыннан анда көн саен «Метеорлар» йөри.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Балык тотарга теләүчеләр өчен – ял базалары, коттеджлар. Бәяләре – 800 дән 21500 сумга кадәр.

НӘРСӘ САТЫП АЛЫРГА:
Француз рецептурасы буенча җитештерелгән җирле камамбер сыры һәм биредә үстерелгән йөзем.

ТАГЫН НӘРСӘ КАРАРГА:
Император питомнигына барырга киңәш итәбез. Биредә 350 га мәйданда агачларның дистәләрчә төре үстерелә, алар арасында Европадан кайтартылган шактый сирәк очрый торган сортлар да бар.
Карамал елгасындагы яңа комлыкта ял итәргә була. Биредә җәйге ял өчен кирәкле бөтен нәрсә – ятаклар, душ кабиналары, волейбол мәйданчыгы, турниклар, чатырлар, пирс, парковка бар...



ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны «Курай» кунакханәсендә алырга була: Кама Тамагы штб, Кооператив ур., 38.

7

АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ: ТАРИХКА ИЗГЕ АЧКЫЧ



Алексеевск районы – җирле бизәкләп туку фабрикасында чигелгән сөлге кебек чуар һәм уңайлы ул. Биредә төрле гасырлардан бик күп дәлилләр сакланып калган, шунлыктан төбәк тарихы яхшы өйрәнелгән. Аның бүгенге мактанычларыннан берсе – ел саен үткәрелә торган «Алексеевские перезвоны» чаң кагу фестивале. Ул Алексеевское шәһәр тибындагы бистәсендә 1996 елда төзелгән Воскресение Христова чиркәве территориясендә уздырыла. Чаң кагуны туйганчы тыңлап хозурлангач, туку фабрикасында борынгы технологияләр буенча кабатланмас бизәкле искиткеч тукымалар җитештерү белән танышырга мөмкин. Төбәкне өйрәнү музеендагы 20 меңгә якын экспонатны кадерләп саклаучылар XVIII гасырда нигез салынган Алексеевскоеның тарихын тәфсилләп сөйләр. Әлеге тарих белән танышканнан соң районның эченәрәк – Биләргә юнәлергә була. Биредә исә кунакларны күренекле химиклар Александр Ерминингельдович һәм Борис Александрович Арбузовларның искиткеч кызыклы музей-йорты көтә. Экспозициянең бер өлеше аларның фәндәге элгәре һәм күршесе Александр Бутлеровка багышланган. Бу борынгы авыл әле Биләр шәһәрлеге (X гасыр-XIII гасырның беренче яртысы) белән дә данлыклы. Биредә сарай (кафедраль) мәчетенең ике заллы комплексы, кәрвансарай, торак йорт, кирпеч мунча нигезләре сакланган. Кайчандыр борынгы Биләр диварлары торган калкулык итәгендәге «Изге чишмә» комплексы территориясендәге тарих-археология музееның уникаль экспонатлары Идел буе Болгарстанындагы иң данлыклы калалардан берсе булган Биләрнең гөрләп үсү һәм аннары җимерелү тарихын сөйли. Парк территориясендә чатырлар, күл һәм саф салкын сулы чишмә үзе урнашкан. «Биләр тәвә кошлары» экофермасына бару исә җирле табигать матурлыклары белән тагын бер кат хозурлану мөмкинлеген бирәчәк. Биредә Австралия һәм Африка токымлы тәвәләр, тәкәббер тавислар, фазаннар һәм сөйкемле йорт куяннары белән юанырга була.

PRESSA



Бер бизәкле сөлгене тукуга берничә көннән алып бер айга кадәр вакыт китәргә мөмкин.

БИЗӘКЛӘП ТУКУ ФАБРИКАСЫ

Алексеевское бистәсенең визит карточкасы туры мәгънәсендә дә, күчерелмә мәгънәсендә дә төрле төстәге җепләрдән тукылган. Туку фабрикасын моннан йөз ел элек сәүдәгәр хатын Макарина төзеткән. Искечә, агач станокларда тукый торган предприятиеләр Россиядә икәү генә – Түбән Новгород өлкәсендә һәм Алексеевское бистәсендә. Предприятие кечкенә булса да, данлыклы – аның эшләнмәләре Россиядә дә, чит илләрдә дә мәгълүм. Казанда югары дәрәҗәле кунакларны каршылаганда чәкчәк тотып торган кызларның кулындагы матур сөлгеләр дә – Алексеевское тукучылары хезмәте. Бер бизәкле сөлгене тукуга берничә көннән алып бер айга кадәр вакыт китәргә мөмкин.

АКАДЕМИК АРБУЗОВЛАР МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Рус химия мәктәбенә нигез салучы, Бутлеровка авылында (хәзер – Татарстанның Алексеевск районы) туган Александр Бутлеровның ике мавыгуы булган: спиритизм һәм чолыкчылык. Умартачылык белән ул җитди шөгыльләнгән, технологияне һаман камилләштереп торган. Мәсәлән, Бутлеров умартага рамнар куя башлаган. Химия өлкәсендә аның фәнни эзләнүләре дәвамчысы Александр Арбузов исә янәшәдәге Арбузов-Баран авылында туган, ул аспирин, сагыз һәм үз исемендәге реакцияне уйлап тапкан. Болар һәм данлыклы якташлары тормышыннан башка күп фактлар белән Арбузовлар музей-йортында танышырга мөмкин. Биредә аларның эш кабинетлары интерьерлары һәм шул замандагы лаборатория әсбаплары сакланган.

БИЛӘР ТАРИХ-АРХИТЕКТУРА МУЗЕЕ

Фондында 1,5 меңнән артыграк экспонат сакланган Биләр тарих-архитектура музеенда борынгы Биләргә кагылышлы күп дәлилләр белән танышырга мөмкин. Төрки гамәли сәнгате символларыннан берсе – якынча XII гасырда ясалган хатын-кызлар чигә бизәгечендәге бик нечкә алтын укалы үрдәк нәкъ менә биредә саклана. Төрки һәм фин-угыр риваятьләреннән мәгълүм булганча, бөек океан төбеннән беренче җир кисәген үрдәк тапкан, шунлыктан мондый бизәнү әйбере бөти ролен дә үтәгән.



Музейда аларның эш кабинетлары интерьерлары һәм шул замандагы лаборатория әсбаплары сакланган.



Үзенчәлеге

ҖИМЕРЕЛГӘН ШӘҺӘР

Салкын саф сулы Изге чишмә Биләрдән биш чакрым ераклыктагы җыйнак паркның уртасында агып ята. Паркта чатырлар, учаклар куелган, зур дини бәйрәмнәрдә мөселманнар биредә аш үткәрә. Әлеге урын юкка гына изге саналмый. Аның янәшәсендәге тауда кайчандыр Идел буе Болгарстаның өч бөек шәһәреннән берсе исәпләнгән Биләр урнашкан булган. 1236 елда, Батый хан гаскәрләренең күпсанлы һөҗүмнәре һәм камалышларыннан соң, Биләр тулысынча җимерелгән. Риваятькә ышансак, Биләр калкулыкларының берсендә кырык гүзәл кыз, хан кызы Алтынчәч җитәкчелегендә, ныгытма төзегән һәм аны дошманнан саклап сугышкан. Һәлак булырга бер мизгел кала кызлар якты йолдызга әйләнгән һәм күккә ашкан. Биләрне саклаучы кырык кыз истәлеге тау башындагы өч ташта мәңгеләштерелгән, аның янына Изге чишмәдән 444 басмалы баскыч буйлап күтәрелергә кирәк. Ташларны өч тапкыр әйләнеп теләк теләсәң, ул һичшиксез тормышка аша, диләр. Ихтимал, бу матур риваять кенәдер, әмма тарихчылар әйтүенчә, бу урын инде бронза чорында ук изге-мөкатдәс булган.

P-239 федераль трассасыннан барган юлчы кунаклар Алексеевское яныннан үткәндә беркайчан да татлы ризык алмый китми.

Тәмлетамакларга

ТОРТЛЫ, ТАТЛЫ БИСТӘ

Алексеевское бистәсендә әзерләнә торган иң тәмле ризык – кондитер эшләнмәләре. Җирле сәүдә комплексында төрле тортлар сатып алырга була. Алар – бистә кондитерларының визит карточкасы. Авызда эри торган ванильле, шоколадлы бисквитлар, баллы-чикләвекле кабартмаларга сеңдерү өчен коньяклы, җимешле, каймаклы ширбәтләр... Ә эчлекләре! Һәртөрле җиләк-җимеш, йогыртлар, күпертелгән сөт өсте, карамель, кайнаткан куертылган сөт, шоколадлы крем, эремчекле һәм каймаклы крем... P-239 федераль трассасыннан барган юлчы кунаклар Алексеевское яныннан үткәндә беркайчан да татлы ризык алмый китми... Җирле кондитерлар пешергән «Графские развалины» торты кебек тәмле нигъмәтне башкалаларда да табып булмый диләр хәтта. Биредә төрле халыкларның милли ашларын яратып һәм оста әзерлиләр. Мәсәлән, әрмән гатасы – уалучан катламлы камырдан атланмайлы-баллы эчлек белән печенье бик тәмле. Алексеевское осталары гади ингредиентлардан әллә нинди катлаулы ризыклар әзерли. Арыш оныннан пилмән (ите – бары тик авылныкы гына), чөгендер, кишер, кәбестә кәтлитләре, махсус мичтә җимеш агачлары йомычкасы төтенендә ысланган түш ите, шулай ук тозлы сельдь, скумбрия, иваси, бөкрәч... – боларны санаганда гына да авыздан сулар килә.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Шәхси автомобильдә. Казаннан Алексеевское бистәсенә кадәр юлга (100 км чамасы) 1,5 сәгать вакыт китә.
Казан–Алексеевское автобусында. «Көньяк» автовокзалыннан китә. 1,5 сәгать бара.

БИЛӘРГӘ НИЧЕК БАРЫРГА:
Алексеевское бистәсеннән шәхси автомобильдә яки таксида. Юлга (42 км) 50 минут вакыт китә.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Хостелда, мотельдә, ял базасында. Бәяләре ике кешегә 1400 сумнан* башлана.

КАЙДА СЫЙЛАНЫРГА:
Җирле кафеларда.

СУВЕНИРЛАР ҺӘМ КҮЧТӘНӘЧЛӘР:
Алексеевск районына барып, төрлечә әзерләнгән Кама балыгыннан авыз итмичә кайту ялгыш булыр. Аны Кама аша салынган күпернең ике башында, җирле кафеларда сатып алырга була.
Алексеевское бизәкләп туку фабрикасында җитештерелгән тастымал, эскәтер, сөлге һәм башка эшләнмәләр теләсә кайсы интерьерга килешә.

** 2021 елның май аендагы бәяләр*



ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны В. И. Абрамов исемендәге Төбәкне өйрәнү музеенда алырга була: Алексеевское штб, Казаков ур., 6А.

PRESSA

8



КУКМАРА:
КҮК ТАУЛАР, АЛЫП ИМӘННӘР ҺӘМ, ӘЛБӘТТӘ, КИЕЗ ИТЕК...

Гадәттә, Кукмара атамасы мари сүзләреннән барлыкка килгән дип санала: «кук (курык)» – ике һәм «марий» – мари кешесе. Галим-әдәбиятчылар «кукмара» сүзенең әдәби тәрҗемәсен алга сөрә – «күк чәчәк». Татарстан Республикасы белән Киров өлкәсе чигендәге кечкенә шәһәр Казаннан 115 чакрым ераклыкта урнашкан. Шәһәрчеккә Явыз Иван гаскәрләреннән качып килгән мари кешеләре нигез салуы – тарихи факт. Ә инде анда төпләнүче халык арасында удмуртлар да, татарлар да булган. Бүген дә Кукмарада төрле милләт вәкилләре дус һәм тату гомер итә, үзләрен алар, горурланып, «кукмаралар» дип атап йөртә.

Парижның шәһәрне бар дөньяга танытткан Эйфель манарасы, Лондонның БигБены бар, ә Кукмараны «Кукмара тавы» ландшафтлы табигать һәйкәле һәм... киез итек данлый. Икесе дә шәһәр гербында урын тапкан. Милли бизәкле аяк киемнәре, билгеле ки, районнагы борынгыдан килгән киез итек басу кәсебенә ишарә. Бүген җирле осталарның итекләре республикадан еракларда да мәгълүм һәм данлыклы.

Кукмара районы чишмәләргә дә бик бай. Шулардан берсе – «Күз чишмәсе» Ятмас Дусай авылы янында агып ята. Дәвалау үзлекләренә ия булган саф сулы чишмә Кукмарага халыкны бөтен Россиядән җәлеп итә.

Биредә тарих, архитектура һәм ландшафтлы табигать һәйкәлләре шулкадәр күп ки, күңелсезләнеп утырырга вакыт калмаячак.

Кипрда изгеләндерелгән могҗизалы иконалар тулы Петропавел (Петр һәм Павел) чиркәве. Зур Кукмара авылындагы комлы токым катламнарының «космик пейзажлары»: алар янында сурәткә төшсәгез, истәлеккә матур да, кызыклы да фотолар калыр. Язучы Чыңгыз Айтматов талантына мөкиббәннәр исә Мәчкәрәгә, язучының нәсел шәҗәрәсе башланган авылга бара ала.

Әлеге бина – XIX гасыр бай сәүдәгәрләре һәм эшкуарларының шәһәрдәге күп бүлмәле йортларына типик мисал булып тора.

XX гасырның 60 нчы елларында җирле халык такыр тау битләренә меңләгән нарат һәм каен үсентесе утырткан.



Истәлекле урыннар

БЕРТУГАН КОМАРОВЛАР ЙОРТЫ

Кукмара итекләре җитештерүче һәм сатучы бертуганнарның төп йорты – мәдәни мирас объекты. Әлеге йорт гасыр ярымнан артык тарихка ия. Әйтерсең лә, йорт хуҗалары вакытлыча гына үзләренең сәүдә эше буенча киткән дә, менә-менә кайтып керер сыман. Ә кичен зур гаилә камин каршында җыелыр. Ул әле бүген дә кабызганны гына көтеп тора төсле...

Әлеге бина – XIX гасыр бай сәүдәгәрләре һәм эшкуарларының шәһәрдәге күп бүлмәле йортларына типик мисал булып тора.

КУКМАРА ТАВЫ

Аны әле тагын «Яшел хәзинә» дип тә йөртәләр. Әмма ул һәрвакытта да яшел булмаган. XX гасырның 60 нчы елларында җирле халык такыр тау битләренә меңләгән нарат һәм каен үсентесе утырткан. Ялан тау куе яшел урманга әйләнгән. Искиткеч гүзәл табигать һәйкәленең барлыкка килү тарихы әнә шундый. Кышын бирегә экстрим яратучылар тау чаңгысында, сноубордта шуарга килә. Тау башыннан Кукмара һәм аның тирә-ягына сихри манзара ачыла.

КҮП ГАСЫРЛЫК ИМӘН

Алып имән Ятмас Дусай һәм Төркәш авыллары арасында үсә. Аның биеклеге 24 метр тәшкил итә, диаметры исә 5 метрга якын. Белгечләр әйтүенчә, имәнгә якынча 300 яшь, әмма җирле урманчылар каршы чыга – 500 елдан да ким түгел, диләр. Йөзьяшәр имәнне җирле халык көч-куәт бирү үзлегенә ия, дип саный. Бу баһадир имән нинди генә тарихи вакыйгаларның шаһите булмагандыр...

КУКМАРА ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ

1870 нче елларда бу бинада бертуган Родигиннарның киез итек басу фабрикасы эшләгән. Әһәмияте буенча ул бертуган Комаровлар предприятиесеннән кала Казан губернасында икенче урында торган. 1917 елга кадәр шулай булган.

Бүген бинада төбәкне өйрәнү музее эшли. Родигиннар йортында инде хәзер аларның көндәше түгел, бәлки тарихи хезмәттәше булган бертуган Комаровларның эшләнмәләре экспонат буларак урын алган. Володиннар остаханәсе самоварлары, бакыр поднослары да бар. Кызыклы тарихи истәлекләр бик күп монда, чөнки Кукмара һәрвакыт осталары белән дан тоткан.

Белгечләр әйтүенчә, имәнгә якынча 300 яшь, әмма җирле урманчылар каршы чыга – 500 елдан да ким түгел, диләр.



1870 нче елларда бу бинада бертуган Родигиннарның киез итек басу фабрикасы эшләгән. Әһәмияте буенча ул бертуган Комаровлар предприятиесеннән кала Казан губернасында икенче урында торган. 1917 елга кадәр шулай булган.

PRESSA

Кукмарада елына 1,5 миллион (!) пар аяк киеме басалар.

Үзенчәлеге

ҖЫЛЫ БРЕНД

Ни генә дисәгез дә, кыш өчен киез итектән дә җылырак аяк киеме уйлап табучы юк әле. Хәтта иң югары технологияләр нигезендә җитештерелгән күн итек тә киез итеккә тиңләшә алмас. Ә Кукмара итекләре – ул инде бренд кына түгел, бәлки тулы бер фәлсәфә. Гади сарык йоныннан итек басу технологиясе гасырлар дәвамында тамчы да үзгәрмәгән. Яхшырагын уйлап табучы юк чөнки! 150 елдан артык тарихка ия итек басу фабрикасына аяк баскан чит ил вәкилләре аптырашта кала: ни өчен бу киез итекләрнең бер җөе дә юк соң? Җавап гади – моның сере элгәрләрдән мирас булып калган технологиядә.

Гасыр ярым дәвамында киез итек баскан җирлекнең үз фестивале барлыкка килмәсә, сәер булыр иде. Бар ул – «Кукмара итекләре» – #ITEKFEST». Башта бәйрәмне итек басу һөнәренә кызыксыну уяту, һөнәрчелек турында сөйләү, яшьләргә киез һәм тула серләрен өйрәтү өчен оештырсалар, елдан-ел анда катнашучылар саны арта гына барган. Биредә төрле кәсепләрне күрсәтәләр. Фестивальдә катнашырга дип, Россиянең төрле почмакларыннан гариза җибәрәләр Кукмарага. Яшен-картын үзенә җыйган фестиваль көнозын дәвам итә.

Туристлар #ITEKFESTның ярминкә рәтләрен көнозын таптый. Кукмарада елына 1,5 миллион (!) пар аяк киеме басалар. Кунаклар, бигрәк тә гүзәл затлар, ярминкәдә акчаларын кызганмый, чөнки мондагы кебек киез һәм тула итек, угги, ботинка, үкчәле итек, пима, калош һәм тагын әллә ничә төр продукцияне башка беркайда да очрату мөмкин түгел! Кыш көне, фестиваль вакытында гына түгел, ел әйләнәсе сатыла алар биредә.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Автомобильдә. Казаннан Теләче, Байлар Сабасы, Арча, Балтач аша юлны 1,5 сәгатьтә узарга мөмкин.
Электричкада. Казан–Пассажирлар тимер юл станциясеннән көнгә берничә тапкыр китә. Билет бәясе – 218 сум.

НӘРСӘ АЛЫП КИТӘРГӘ:
Данлыклы Кукмара киез итеге һәм металл савыт-саба. Атаклы хуш исле борай икмәге, җирле лимонад. Натураль продуктларга өстенлек бирсәгез – җирле умарталыклардан чәчәк балы һәм умарталык продукциясе, фермер хуҗалыклары җитештергән казылык.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кукмарадагы хостел, кунакханә һәм кунак йортларында төн куну туристларга 500 дән алып 2500 сумга кадар төшә.

КАЙДА СЫЙЛАНЫРГА:
Кафеларда. Уртача чек 250 сумнан башлана.

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Кукмара төбәкне өйрәнү музеенда алырга була: Кукмара штб, Ленин ур., 8.

PRESSA

АЛАБУГА:
ҮТКӘНГӘ СӘЯХӘТ



Әгәр сез узган гасырларга сәяхәт кылырга ниятләгәнсез икән – бирегә рәхим итегез. Чулман һәм Тойма елгалары кисешкән урындагы гүзәл кала – борынгылыкны яратучылар өчен менә дигән хәзинә. Алабуганың Казан, Яр буе, Зур Покрау урамнарында XIX гасыр өяз каласының йокымсыраулы рәхәт патшалыгына эләгәсең. Купшы-пөхтә сәүдәгәр утарлары, табыш йортлары, сәүдә рәтләре – вакыт аларга бөтенләй кагылмаган диярсең. Такталарга кызыклы атамалар язылган – «Хлебец», «Мясная лавка», «ТрактирЪ». Һәм бу гасырлар буе сакланып калган искиткеч затлы биналарга ике метрлы, чуен башлы городовой өстән хуҗаларча сокланып карап тора...

Әле бит шул ук «ТрактирЪ» нинди дә булса декорация генә дә түгел, ә бәлки чын трактир, төгәлрәге, «ТрактирЪ» музей-театры. Һәм бөек Иван Шишкин музее да ниндидер күчермәләр тупланмасы түгел, ә бәлки рәссам туып-үскән һәм иҗат белән шөгыльләнгән, шул замандагы бөтен җиһаз-җайланмасы кадерләп сакланган чын йорт үзе.

Алабугада бөтен нәрсә чын һәм уникаль. Кутузовның ординарецы, данлыклы кавалерист кыз Надежда Дурованың картайган көнендә кәнәфиендә төрепкә тартып утырган агач йорты. Яше күптән мең елдан арткан борынгы болгар манарасы. Моннан ике гасыр элек төзелеп, безнең көннәргә кадәр сакланып калган дөньяда бердәнбер җәмәгать кер юу йорты.

Ә тирә-юнь? Танаев урманы, Кызыл Тау, әкияттәгедәй гүзәл Чулман күренешләре... – боларның барысын да Иван Шишкин кайчандыр үз картиналарында мәңгеләштергән. Ялкауланмасаң, барлык бу гүзәллек белән Алабугада хәзер дә хозурланып була, «Түбән Чулман» милли паркының экологик сукмакларыннан үтәргә генә кирәк. Бераз гына үҗәтлек күрсәтсәгез, моннан йөз илле ел чамасы элек рәссамны кулына кылкаләм алырга һәм «Вид на Каму близ Елабуги», «Сосновый бор» яки «Корабельная роща» картиналарын язарга мәҗбүр иткән урыннарны эзләп табарга була әле...

Тагын бер нәрсәне әйтү мөһим: Алабугада өйдәге кебек уңайлы. Шәһәр үзәгендәге кунакханәдә тукталсагыз да, иртән сез әтәч кычкырган тавышка уяначаксыз. Тагын кайда шулай иртән портье түгел, ә мактанчык әтәчләр хоры уятыр иде әле үзегезне?



Иван Иванович Шишкин, иртәнге пленэрдан кайткач, әлеге йортның болдырында утырырга яраткан.

Истәлекле урыннар

АЛАБУГА (ШАЙТАН) ШӘҺӘРЛЕГЕ МАНАРАСЫ

Рус сәүдәгәрләре каласы моннан мең ел элек болгар әмире нигез салган урында калыккан. Шәһәрлек – биек калкулыктагы шул бистәнең калдыклары. Алабуганың иң истәлекле урыны – Алабуга шәһәрлеге манарасы да шул заманнан калган. Әлеге манараны монголларга кадәрге болгарларның безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер архитектура ядкәре, диләр. Сүз уңаенда шуны да әйтү урынлы булыр: башка шәһәр халкы белән бергә, рәссам Иван Шишкинның әтисе 1867 елда хәрабәләрдән яңадан торгызган аны.

ШИШКИН МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

Иван Иванович Шишкин, иртәнге пленэрдан кайткач, әлеге йортның болдырында утырырга яраткан. Шунысы кызганыч: гасыр ярымлык ара аның зур, көчле кулын хөрмәтләп кысу мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Кулының зур булуы төгәл билгеле: «Утро в сосновом лесу», «Среди долины ровныя», «Перед грозой» картиналарын һәм башка җәүһәрләрне иҗат иткән Оста кулының исән чагында төшерелгән кучермәсе биредә саклана. Ике катлы зиннәтле йортны исә бөек рәссамның әтисе – икмәк сәүдәсе белән шөгыльләнгән икенче гильдия сәүдәгәре, берара шәһәр башлыгы булып торган Иван Васильевич Шишкин төзеткән.

БЕХТЕРЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ӨЯЗ МЕДИЦИНА МУЗЕЕ

Земство хастаханәсенең агач бинасы 1881 елда сәүдәгәр Баранов акчасына салынган. Карболка исе сеңгән диварлардагы экспозициядән шул замандагы дәвалау чаралары белән танышып була. Биредә дару препаратлары әзерләү өчен кечкенә фарфор киле һәм килесап та, әзер дарулар да бар. «VALIDOL» – дип язылган берсенә. Астарак сәер аңлатма: «Противъ желудочныхЪ недомоганій». Әлбәттә, бүген язылган рецепт түгел инде, ул – «изъ Земской Аптеки 1883 1/10 года»...

Үзенчәлеге

«ЧЕБЕН» ФИЛДӘН ДӘ ШӘБРӘК ОЧРАК

«ТрактирЪ» музей-театры түрендә, аерым витринада, пыяла астында, Корал пулатындагы Россия империясе таҗы кебек диярлек, Алабуга өчен аеруча кыйммәтле экспонат саклана. Бу – өч йөз еллык раритет чәркәсе, аны русча «муха» дип йөрткәннәр.

Әлеге чәркәнең пәйда булу тарихы Россиядәге эчкечелек тарихыннан аерылгысыз. Янәсе, Петр патша, гади халыкны трактирларга иялләштерер өчен, анда килүчеләргә беренче чәркәне бушлай бирергә боерган, ди. Хуҗалар патша фәрманына каршы чыгарга базмый, әмма нибары бер аш кашыгы чамасы – 10–15 грамм эчемлек кенә сыя торган чәркә уйлап таба. Халык аңа шундук «муха» дигән кушамат тага.

Хәер, бу аеруча зирәкләргә туйганчы бушлай эчәргә бер дә комачауламый – алар берничә трактирга рәттән кереп чыга торган була. Алабуга музейчылары үз фондларындагы хәзинә арасыннан нәкъ менә шул чәркәне казып чыгара да, бу һөнәр ияләренә бик үк хас булмаган җитезлек һәм булдыклылык күрсәтеп, тиз арада патент та алып куя. Хәзер биредә килүче кунакларны эксклюзив савыт белән гаҗәпләндереп кенә калмыйлар – сувенир чәркәне сату хокукына бары тик алабугалар гына ия.

Риваять

Күрәзәсе өчен еланга кеше гомере белән түләргә кирәк булган – аңа әсирлеккә төшкән дошманнарны корбан иткәннәр.

КҮРӘЗӘЧЕ ЕЛАН

Риваять буенча, Алабуга (Шайтан) шәһәрлеге атамасы биек калкулыктагы мәҗүси гыйбадәтханәдә яшәгән күрәзәче еланга бәйле. Язмышын белергә теләүчеләр елан янына агылган. Күрәзәсе өчен еланга кеше гомере белән түләргә кирәк булган – аңа әсирлеккә төшкән дошманнарны корбан иткәннәр.

Әмма бервакыт елан юкка чыккан. Бу Болгар дәүләте җимерелер алдыннан булган. Һәм үз ватанын һәм үз халкын ыргылып килгән дошманнан ничек коткарып калу ысулын хан беркемнән дә сорый алмаган...

Сүз уңаенда, Алабуга шәһәрлегенә күрәзәче елан әйләнеп кайткан бит. 2016 елның августында. Бронзадан ясалганы.

Тәмлетамакларга

ЦВЕТАЕВАНЫҢ АЛМА БӘЛЕШЕ

Алабугада сезне һичшиксез искиткеч тәмле каймаклы алма бәлеше белән сыйлаячаклар һәм аның нәкъ менә Марина Цветаева рецепты буенча әзерләнүенә ышандырырга тырышачаклар. Көмеш гасыр шагыйренең ашарга пешерергә яратмавын искә төшереп каршы әйтә күрмәгез тагын үзләренә. Бу шәһәрдә бакыйлыкка күчкән Цветаева истәлеген кадерләп саклаган алабугалар да белмәсә, кем белсен ди бу хакыйкатьне?

Әйе, безгә мәгълүм: ризыкка гомумән битарафрак булган Цветаева, бервакыт пешекчесе нәрсә әзерләргә дип сорагач, рецептлар китабының бер битенә төртеп күрсәткән, ди. Нәтиҗәдә мескен пешекчедән бөтен базар халкы көлгән – хуҗасы кушкан ризыкны пешерер өчен, ул кабан дуңгызының башын эзләп йөргән, имеш... Әмма тарих Маринаның сеңлесе Анастасия Цветаеваның Тарусадагы рәхәт тормышлары турындагы хатирәләрен дә саклый: «Веранда, где вечно кипел на столе самовар, жужжали над вазочками с разнородным вареньем и медом осы, сладкие пироги, ватрушки – и особенно любимые ржаные сдобные лепешки, которые пекла на сметане пожилая ласковая Катя...»

Ихтимал, нәкъ менә Тарусадагы тормышлары хакында хатирәләр апа белән сеңелнең «каймаклы бәлешне» гаилә ризыгы итүенә сәбәп булгандыр. Еллар узгач, инде Маринаның кызы Ариадна Эфрон да Раштуа бәйрәменә үзенең «алма һәм каймаклы крем белән бөккән» пешерүен сөйләячәк.

Әлеге искиткеч тәмле ризыкны пешерү өчен гайре табигый бернәрсә дә таләп ителми. Бары тик татлы камыр, каймаклы кремсоус һәм Антонов алмалары гына кирәк. Табигый ки, төп ингредиент уйчан-назлы «цветаевча» кәеф булырга тиеш.

ЦВЕТАЕВА БӘЛЕШЕ РЕЦЕПТЫ

Камыр өчен: 2 стакан он, яртышар стакан каймак һәм шикәр, 150 грамм атланмай, 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч.

Өстенә агызу өчен: 1әр стакан каймак һәм шикәр, 1 йомырка, 2 аш кашыгы он.

Эчлек: 1 килограмм алма.

Әзерләү: шикәрне каймак белән туглыйлар, эретелгән атланмай, он һәм камыр көпшәкләндергеч өстәп, камыр басалар. Табага җәеп, кырыйларын күтәртәләр дә, туралган алманы матурлап тезеп, өстенә каймак-шикәр-йомырканы яхшылап туглап агызалар. 180 градуслы газ мичендә 1 сәгать пешерәләр.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан М7 трассасы буйлап Алабуга борылышына кадәр. Ара-208 км.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кунакханәдә, кунак йортында яки хостелда. Бәяләр – хостелда тәүлегенә ике кешегә 800 сумнан алып дүрт йолдызлы кунакханәдә ике кешегә (иртәнге аш белән) тәүлегенә 2890 сумга кадәр.

НӘРСӘ КАРАРГА:
Борис Березовскийның «Летние вечера в Елабуге» традицион Халыкара музыка фестивале. 15, 16, 17, 18 июльдә һәрвакыттагыча open-air форматында узачак. Катнашучылар арасында виолончельче Александр Князев, Бельгиядән килгән музыкаль квартет, Игорь Скляров җитәкчелегендәге «Crystal Trio» ансамбле, Александр Суетин җитәкчелегендәге «Мадригал» борынгы музыка ансамбле, Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге «La Primavera» камера оркестры булачак.
Бөтенроссия Спас ярминкәсе. 6,7,8 август. Анда Россия Федерациясеннән һәм якын вә ерак чит илләрдән килгән декоратив-гамәли сәнгать, халык нәфис һөнәрчелеге осталары катнаша.

НӘРСӘ САТЫП АЛЫРГА:
Җирле осталарның чыбыктан һәм каен тузыннан ясалган эшләнмәләре, бөтиләр. Бары тик Алабугада гына сатыла торган оригиналь сувенир – «муха» чәркәсе. Патша Россиясе трактирларында мондый чәркәгә эчемлекне бушлай салып биргәннәр.

УЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Алабуга дәүләт музей-тыюлыгының Шәһәр тарихы музеенда алырга була: Алабуга, ш., Гассар ур., 9.

10

АРЧА РАЙОНЫ. ӘКИЯТЛӘР ҺӘМ КЫШ БАБАЙ ИЛЕ

Казан арты, әдәби башкала, Милли Мәккә, Әдәбият каласы... Ничек кенә атамыйлар Арча җирен. Һәм алар барысы да җисеменә туры килә – җиһанга бөек мәгърифәтчеләр Курсави, Мәрҗанине, даһи Тукайны бүләк иткән як бу. Гасырлар дәвамында күп фаҗига кичерсә дә, үзенең милли йөзен, кыйбласын югалтмаган төбәк.

Арча районында бүген 52 меңнән артык кеше яши, шуның 12 меңе – Арча шәһәрендә. Барлыгы 128 авыл бар. Нигездә татарлар гомер итә – 92 процент. Район территориясендә 23 елга һәм инеш исәпләнә, иң озыны – Казансу. Аның озынлыгы 140 чакрым тәшкил итә.

Арча шәһәре Казаннан нибары 60 чакрым ераклыкта урнашкан. Ике арада тимер юл (1893 елда Арча аша беренче товар поезды китә.) һәм автомобиль магистрале бар, шунлыктан туристларга бирегә килеп җитүе бик ансат.

Биредә истәлекле урыннар һәм карар җирләр бик күп, чөнки Арча – республикадагы иң борынгы шәһәрләрдән берсе.

Тарихи факт: Явыз Иван гаскәре, Казанны яулаганчы, башта Арчага юнәлә (1552 елның сентябрендә). Тик Арча тиз генә бирешми, дүрт елга якын сугыш бара бирәдә. Нәтиҗәдә, Казанда яшәүче күп татар зыялылары Арчага, якын-тирә авылларга күченә. Максатлары – татарлар бер җирдәрәк яшәргә уйлый.

PRESSA

Элеккеге Арча кирмәне урынында 2016 елда бик матур парк ачылган. Мәйданы – 13 гектар. Берничә зонага бүленгән паркта һәркем үз күңеленә хуш килгән урын таба ала.

Истәлекле урыннар

«КАЗАНСУ» ПАРКЫ

Элеккеге Арча кирмәне урынында 2016 елда бик матур парк ачылган. Мәйданы – 13 гектар. Берничә зонага бүленгән паркта һәркем үз күңеленә хуш килгән урын таба ала. Ачык һавада бассейн, кызыну ятаклары, сәламәт яшәү рәвеше тарафдарлары өчен – заманча тренажерлар, рәхәтләнеп сәламәтлегеңне ныгыт. Кечкенәләр өчен аерым мәйданчык бар. Монда яраткан татар әкиятләре геройлары – Су анасы, Шүрәле, Кәҗә белән Сарыкны очратырга мөмкин. Кыскасы, паркта ялны файдалы, күңелле итеп үткәрү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

МОГҖИЗАЛАР УРМАНЫ

Арчага килүче туристлар арасында җәен дә, кышын да иң популяр юнәлеш – Кушлавыч–Кырлай маршруты. Кырлайда җәен дә, кышын да ял итәргә була.

Ел әйләнәсе музей, кунакханә эшли. Теләгән кешегә мунча керергә, атта, көймәдә йөрергә мөмкин. Ә балаларны Могҗизалар урманы кызыктыра. Биредә сабыйларны чын Кыш Бабай каршы ала. «Могҗизалы урман»да малай-кызлар өчен квест уен оештырыла. Мажаралар үрмәкүч оясыннан башлана. Убырлы Карчык йортында малай-кызларны әллә нинди сәер хәлләр көтеп тора. Биредә һәр әйбер тылсым белән сугарылган – хәтта күлдә дә җеннәр «яши».

Балаларны Могҗизалар урманы кызыктыра. Биредә сабыйларны чын Кыш Бабай каршы ала.

Үзенчәлеге

ӘЛИФБА МУЗЕЕ

Арчада Әлифба музее бар. Ул Россиядә бердәнбер. Алай гына да түгел, музей хезмәткәрләре аны, дөньяда бер генә, диләр. Шуңа күрә дә аларга Норвегия,Финляндия, Германия, Франция, Италия, АКШ, Кытай һәм башка илләрдән экскурсиягә киләләр. Кунаклар, беренче эш итеп, туган телләрендәге әлифбаны эзли башлый. Ингушетиянең мәгариф министры кебек. Әлеге дәрәҗәле кунак Арчага килгәч, махсус Әлифба музеена тукталган. «Сезнең хакта интернеттан укып белдем. Музейда ингуш телендәге әлифба бармы?» – дип сораган.

Бик күп әлифба арасыннан ингуш телендәгесен табып биргәч: «Бу бит мин укыган Әлифба», – дип әй сөенгән министр! Музей хезмәткәрләре белән ул якын туганнарыдай саубуллашкан.

Бүген музей экспозициясендә төрле телләр басылган җитмешкә якын әлифба бар. Егерме ике ел элек, музейны оештырганда, ул болай дан казаныр дип уйлаучы булдымы икән? Ниятнең һәм эшнең башы татар әлифбасы авторлары – Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитовага барып тоташа. Мөгаллимнәр, эштән киткәндә, Арча педагогика көллиятенә «үз» әлифбаларын, башка кадерле ядкәрләрне бүләк итә. Шул вакытта көллият коллективы, үзара киңәшләшкәннән соң, Әлифба музее булдырырга карар кыла.

Музей экспозициясендә төрле телләрдә басылган җитмешкә якын әлифба бар. Әлифба музее моннан егерме ике ел элек оештырыла.

Тәмлетамакларга

КЫШ БАБАЙДАН ТУТЫРГАН ТАВЫК

Әгәр сәяхәт вакытында сыйланырга яратасыз икән, «Татарстан» Яңа елда турыдан-туры Арча районына – Кыш Бабай резиденциясенә юл тотарга киңәш итә. Ул вакытта сез татар милли ашларын тәгамләп карау белән бергә, Кыш бабай ясаган тутырган тавыктан да авыз итә алачаксыз.

Әлбәттә, Кыш Бабай моны тылсымлы ашъяулыгын җәеп кенә, артык көч түкмичә дә эшли алыр иде, тик бу кемгә кызык булсын. Тылсымлы ашъяулык ярдәмендә кем дә эшли ала! Кыш Бабайның кунаклар өчен бәйрәм сыен борынгы ысул белән, сихер-тылсымларсыз гына эшләп күрсәтәсе килә...

Өстәвенә, ул чын тәмлетамак та икән, Удмуртиядән Тол Бабай, Карелиядән Паккайне, Финляндиядән Йоулупукки, Болгариядән Дядо Мраз туганнары кебек туңдырмага гына риза түгел. Милли ризыклар: чәкчәк, өчпочмак, гөбәдия, бәлеш ярата, каклаган казга мөкиббән китә... Безгә исә әзерләве шактый мәшәкатьле булган ризык – тутырган тавык ясап күрсәтергә булды. Бәйрәм сые! Бары тик кадерле кунаклар өчен генә!

Пешекченең осталыгы тавыкның тиресен итеннән сак кына, ертмыйча аеруда, ит белән тире арасына сөттә тугланган йомырка тутыруда чагыла. Тавыкның түш ите корырак булганга, тәбә аны йомшартачак һәм сусылрак итәчәк. Муенын җеп белән бәйләп, формасын саклар өчен, тавыкны марляга төрә һәм 2 сәгатькә кайнап торган шулпага сала. Тутырган тавыкны турагач, бик матур кисәкләр килеп чыга – иткә төрелгән тәбә!

Тавык пешкән арада Кыш Бабай сезгә үзенең хыялларны ничек тормышка ашыруы турында да сөйләр:

– Күп баланың бүләккә айфон аласы килә. Мондый очракны да хәтерлим: бер кыз миңа хат язган, аны дус кызыннан җибәрттергән, чөнки үзе йөри алмый. Хатны алгач, без барыбыз да бергә авылдагы Зөлфия янына киттек. Безне күрергә бөтен авыл җыелды. Айфон бүләк иттек үзенә. Кыз бик шатланды, ә без аннан да ныграк сөендек. Кешенең яшерен хыялларын тормышка ашыру шулкадәр рәхәт!

Сәеррәк теләкләр дә була: беркөнне бер кыз үзенә өч яңа теш үстерүемне үтенде. Бер ир-ат исә диссертациясен яклаганда ярдәм итүемне теләде! Миннән кияү сораучылар да булгалый...

– Гафу итегез, ә кияүләрне кайдан табасыз?

– Мин тылсымчы бит! Ихластан теләк теләсәң, ул һичшиксез үтәләчәк. Әкият бөтен җирдә бар ул.

– Балалар ничә яшьтән Дед Мороз һәм Кыш Бабайларга ышанмый башлый? – дип кызыксынабыз.

– Төрлечә булырга мөмкин. Менә мин күптән түгел 33 яшьлек хатын-кыздан хат алдым. «Мин синең барлыгыңа ышанам, Кыш Бабай, – дип яза ул. – Һәрвакыт могҗизага ышандым!» Ул миннән бернәрсә дә сорамаган, үземә генә сәламәтлек теләгән. Мин укыганда эреп китә яздым. Күңелебез белән без барыбыз да – бала-чага. Әгәр могҗизага, әкияткә ышанмасак, Татарстаныбыз шундый бай, яшәү өчен шундый уңайлы булыр идемени? Юктыр мөгаен. Өмет тә, тырышлык та кирәк.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казан–Малмыж трассасы белән туры барырга (автобус, автомобиль, электричка).

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Арча яки Кырлайда кунакханәдә. Бәя – ике кешегә 1500 сумнан башлана.

НӘРСӘ КАРАРГА:
Арча Сабан туен. Нәкъ менә биредәге Сабан туенда Россиянең беренче Президенты Борис Ельцин күзен бәйләп чүлмәк ваткан иде.

АРЧАДАН НӘРСӘ АЛЫП КАЙТЫРГА:
Арчаның үзендә ясалган төрле сырлар, камыр ризыклары. Шулай ук Арча милли түбәтәй, читек-чүәкләр ясау буенча да дан казанган төбәк. Болардан да шәбрәк сувенир булуы мөмкин түгел инде!

ҮЗЕҢНЕҢ ТУРИСТЛЫК КАРТАҢНЫ ТУПЛА!

Бу ябыштыргычны Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музееннан алырга була: Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 4.

ТУКАЙ ТӨБӘГЕ

Татар милләтен Тукайсыз күз алдына китереп буламы? Юк, әлбәттә! Тукай безнең тарих та, бүгенге дә. Ул бөтен милләт горурлыгы. Ә арчалылар өчен – өчләтә, бишләтә горурлык.

Арча җиренә аяк баскач та, аның татар әдәбияты классикларын биргән төбәк икәнлеген аңлыйсың. Арча шәһәре үзәгендә урнашкан Язучылар аллеясында сине Габдулла Тукай, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Галиәсгар Камал сыннары «сәламли». Һәркайсының туган авылында музей эшли.

Табигый ки, Арчага килүчеләрнең күбесе Тукай белән кызыксына. Шагыйрьнең туган нигезе кайда? Җырлый торган тавыклары булган Кырлай бүген ничек яши? Һәм башкалар...

Әлеге сорауларга җавап табу авыр түгел – биредә туристлар өчен махсус маршрут булдырганнар. Кунаклар иң әүвәл шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта Тукаевларның музей-йортын карый. Шулай ук Габдулланың этисе Мөхәммәтгариф каберен зиярәт кыла. Аннан соң Кырлайга юнәлә. Монда инде, кем әйтмешли, барысы да бар: Тукай музеена сәяхәт, ресторанда ашау, кирәк кешегә – мунчасы. Кунакханә дә шунда ук. Атналар буена килеп яшәүчеләр бар икән.

– Берничә гаилә ел саен килә,- ди Кырлай музее җитәкчесе Дамир Абдуллин. – Махсус сораганым бар: «Кырлай безгә дә, балаларга да бик ошый. Табигате генә ни тора», – диләр. Чынлап та, бездә ял итү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

Яңа Кырлайдагы Габдулла Тукай музеена кырык ел тулган. Әлеге ике катлы бинаны заманында Бакый Урманченың уникаль проекты буенча салганнар. Татар монументаль сәнгатенә нигез салучы күренекле рәссам, Яңа Кырлайда яшәп, мари урманнарына үзе барып, бүрәнәләрне үзе сайлап алып кайткан. Бакый Урманче тәфсилләп Тукай биографиясен генә түгел, җирле халык белән аралашып, аларның мәдәнияте һәм көнкүрешен дә өйрәнгән. Кырлайлар аны хәзер дә тирән хөрмәт белән искә ала.

– Бакый ага үз эшенең чын остасы булган. Өлгергән агачларны гына алып кайткан, шуңа күрә бүрәнәләр бүген дә бер дигән тора, хәтта ярылган урыннары да юк, – ди музей җитәкчесе.

Габдулла Тукайның 135 еллыгы уңаеннан музейга ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов килгән. Зур чарада шулай ук бүтән мәртәбәле кунаклар да катнашкан. Нәкъ шул көнне Кырлай музеен төзекләндерү турында сүз булган. Якындагы берничә ел эчендә биредә зур үзгәрешләр көтелә.

– Узган ел пандемия сәбәпле музей ике айга ябылып торды, – ди Дамир Абдуллин. – Аннан музейлар көненә – 18 майда гына ачылдык. Аңлашыла ки, узган ел туристлар саны да кимеде, музейга нибары 8 мең 300 кеше килде. Ә алдагы елларда якынча 40 мең була иде. Быел элеккеге дәрәҗәгә кайтмасак та, халык саны күзгә күренеп арта. Әлбәттә, Габдулла Тукайның тууына 135 ел булу да моңа этәргеч ясыйдыр. Президент килеп китү дә зур дәрәҗә. Быел туристлар саны 30 меңнән дә ким булмас, дип уйлыйбыз.

Рөстәм Миңнехановның Кырлай музеена беренче генә килүе түгел. 2016 елда да ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән Кырлайда булып киткән. Минтимер Шәрип улы исә үз вакытында Яңа Кырлайда комплекс төзүне башлаган.

– Бүген безгә күбрәк гаиләләре белән киләләр, – дип дәвам итә сүзен Дамир Абдуллин. – Ә моннан ун еллар элек ешрак мәктәп балалары йөри иде. Хәер, хәзер дә укучылар күп йөри, аеруча – каникулда. Республиканың төрле районнарыннан киләләр. Хәзер бездә «урак өсте» башланды инде.

...Кырлай гаҗәеп табигате белән сокландыра. Хәтта авыл эче дә әкияттәге урманны хәтерләтә. Балык тоту, коену өчен елгасы булган һәм хәтта «тавыклары җырлай» торган искиткеч төбәк бит бу!

Фото: Лилиана Вәлитова. Реклама.

СЕЗ КҮРЕРГӘ ТИЕШЛЕ ВАКЫЙГАЛАР /

Татарстан үзенең Сабантуе белән генә данлыклы түгел. Республикада ел әйләнәсе төрледән-төрле чаралар үткәрелә – үзенчәлекле, кызыклы, шау-шулы, милли! Сезгә ярдәмгә «Татарстан» календарен тәкъдим итәбез. Җаныгыз теләгәнен сайлагыз да кунакка рәхим итегез!

...ЗӨЯ МАЙ ЧАБУ БӘЙРӘМЕНӘ
кышны озату, язны каршы алу бәйрәмендә катнашырга, Зөя коймакларыннан авыз итәргә...

...СПАС ЯРМИНКӘСЕНӘ
Кубачи көмеше, Оренбург мамык шәлләре, Вологда челтәрләре, остакуллар ясаган-үргән агач эшләнмәләр һәм башка матур әйберләр сатып алырга...

...SUNNYFEST БӘЙРӘМЕНӘ
чанада, «мичтә», «танкта» һәм башка шаккаткыч конструкцияләрдә шуарга, рәхәтләнеп күңел ачарга...

...«БӨЕК БОЛГАР» УРТА ГАСЫР СУГЫШЛАРЫ ФЕСТИВАЛЕНӘ
көбә күлмәкләр киеп карарга, кылыч-хәнҗәрләр белән эш итәргә өйрәнергә, урта гасыр бәрелешләрендә катнашырга...

ТУРИСТИК ВАКЫЙГАЛАР КАЛЕНДАРЕ

Май

VOLGA FASHION WEEK ХАЛЫКАРА МОДА АТНАЛЫГЫ

Казан шәһәре

Фото: Александр Ефремов

Июнь

САБАН ТУЕ
ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ
ТӘМАМЛАНУ БӘЙРӘМЕ

Татарстанның барлык авылларында һәм район үзәкләрендә – 12–13 июньдә, Яр Чаллыда – 19 июньдә, Казанда – 26 июньдә.

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

Июль

«АЛАБУГАДА ҖӘЙГЕ КИЧЛӘР»

Россия Федерациясенең атказанган артисты Борис Березовскийның ачык һавада халыкара фестивале.
Алабуга шәһәре

Фото ачык чыганаклардан алынды

Июль

KAZANSUMMIT 2021

2021 елгы саммитның төп темасы – хәләл яшәү рәвеше.
Казан шәһәре

Фото: kazansummit.ru

Июль

MODEST FASHION SHOW

Түгәрәк өстәл
Казан шәһәре

ТУРИСТИК ВАКЫЙГАЛАР КАЛЕНДАРЕ

Август

«КАЗАН ФАНФАРАЛАРЫ»

Тынлы оркестрлар фестивале
Казан шәһәре

Август

БӨТЕНРОССИЯ СПАС ЯРМИНКӘСЕ

Алабуга шәһәре

Август

«БӨЕК БОЛГАР»

Урта гасыр сугышлары фестивале
Болгар шәһәре, Назаровлар ур., 67 нче йорт

Фото «Татарстан» журналы архивыннан

Август

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӘМ КАЗАН КӨНЕ

Казан шәһәре

Фото: Александр Ефремов

Сентябрь

XVII КАЗАН ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ

Казан шәһәре

Фото: kazan-mfmk.com

ЗӨЯДӘ МАЙ ЧАБУ БӘЙРӘМЕ

Уздыру урыны:
«Зөя утрау-шәһәре» музей-тыюлыгы
Вакыты:
март

Бау аша сикерү, аркан тартышу, бүрәнәдә капчык сугышы, киез итек һәм герләр белән йөгереш, гармун һәм сыбызгы-курай көенә әйлән-бәйлән, осталык дәресләре... Монда хәтта борынгыдан калган этеш-төртеш уены да бар, дөрес, күпкә тынычрак рәвештә – команда әгъзалары бер-берсенә ныклы тотынган хәлдә һәм йодрыкларны эшкә җикмичә генә этешә. Күңелсезләнеп, туңып торырга туры килмәячәк. Һәр җирдә милли киемле артистлар, бәйрәм кунаклары каршы ала, рус халык җырлары яңгырый. Иң көчлеләр һәм чыдамнар, атлар булып киенеп, үзәк мәйданга Масленица карачкысын алып чыга.

Ә күңел ачу дәвам итә. Элекке замандагы кебек каурый каләм белән язарга өйрәндеңме, кайрыдан курчак ясадыңмы? Яңа гына мичтән чыккан коймак яки «балта боткасы» белән сыйланып, хәл җыярга вакыт димәк. Карачкы яндырмасаң, нинди Май чабу бәйрәме инде ул? Һай ничек шәп яна! Дөресме-түгелме, карачкы яндырганда теләнгән теләк чынга аша, диләр. Әмма шунысы хак: кышны озатканнан соң, һичшиксез, җылы яз – яңарыш һәм өмет вакыты киләчәк.

КИҢӘШЛӘР:

Май чабу бәйрәменә 20 меңгә якын кеше җыела, мондагы кафеларда алма төшәрлек тә урын булмый. Шунлыктан үзегез белән кайнар чәй яки кофе салынган термос һәм бутербродлар алып килү комачауламас.

Зөянең күптәнге проблемасы– машина кую урыны бик кечкенә, бу исә Май чабу бәйрәме вакытында зур кыенлыклар китереп чыгара. Шуңа күрә иртәрәк килегез: урын да булыр һәм бөкегә дә эләкмәссез.

НИЧЕК БАРЫРГА:

Автомобильдә. Казан белән Зөя арасы – 64 км. Казаннан М 7 трассасы белән Зөя утрау-шәһәре борылышына кадәр барырга кирәк.

СПАС ЯРМИНКӘСЕ

Уздыру урыны:
Алабуга шәһәре
Вакыты:
2021 елның 6–8 августы

Бөтенроссия Спас ярминкәсе чатырлары Алабуганың борынгы өлешендә – Шишкин буалары янында һәм каланың үзәк урамнарында корыла. Ел саен анда 200 меңгә якын кеше катнаша һәм кунак була. Ярминкәне Алабуга сәүдәгәрләре XIX гасыр уртасында ук башлап җибәрә. 1917 елгы инкыйлабка кадәр аңа бөтен Россиядән сәүдәгәрләр җыела торган була. Традиция 2008 елда торгызыла. Хәзер аның төп катнашучылары – Россия һәм чит илләрдән килгән декоратив-гамәли иҗат һәм халык сәнгате һөнәрләре осталары, төрле һөнәрчеләр.

Элекке замандагы кебек үк, ярминкә – кайнап торган сәүдә урыны гына түгел, якты, җете бәйрәм дә ул. Биредә профессиональ артистлар һәм фольклор коллективлары чыгыш ясый, аттракционнар эшли, берсеннән-берсе тәмле ризыклар әзерләнә. Үз эшенең танылган осталары, теләге булган һәркемгә осталык дәресләре уздырып, һөнәр серләрен ача. Ә һич тиңсез һәм кабатланмас товарларның күплегеннән баш әйләнә. Сатуда – иң яхшы әйберләр генә, аларның күбесе– хендмейд, ягъни кулдан ясалган. Кубачи көмеше, Кәсле чуеннары, Оренбургның мамык шәлләре, Вологда челтәрләре, гжель, Ростов финифте; юкә кайрысы, пыяла, тал-йөзем чыбыгыннан ясалган әйберләр... – күзләр камаша. Шул ук гжель – Гжельнең үзендәгегә караганда арзанрак булганда, ә кара йөгертелгән көмеш Кубачидагыдан кыйммәтрәк түгел икән, алмыйча ничек түзеп торасың, ди?

Алыш-бирештән туеп киттегезме? Соң тирә-якта төрледән-төрле кызык нәрсәләр шулкадәр күп ләбаса! Ярминкә көннәрендә сезне Бөтенроссия кыңгырау чыңы фестивале, борынгы рус музыка кораллары осталары концертлары, борынгы шәһәрнең музейлары һәм урамнары буйлап сәяхәтләр көтә.

КИҢӘШЛӘР:
Алыш-бирештән арыгансыз икән, Бөтенроссия кыңгырау чыңы фестивалена юл тота аласыз, борынгы рус музыка кораллары осталарының концертларын карарга, борынгы Алабуганың музейлары һәм урамнары буйлап сәяхәт кылырга була. Фестиваль һәм концертлар – Спас ярминкәсенең аерылгысыз өлеше.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан М 7 трассасы белән Алабуга борылышына кадәр.

SUNNYFEST

Уздыру урыны: Мамадыш шәһәре, Совет ур.
Вакыты: февраль

Иң борынгы күңел ачу төре – таудан чана шууны Мамадышта Россиянең иң кызыклы, әллә каян кычкырып, шаккатырып торган фестивальләреннән берсенә әйләндергәннәр. Кайнар глинтвейн, кул эшләре ярминкәсе, болан яки хаски җигелгән чаналарда йөрү, кызыклы фотосессияләр... Быел әле биредә ике метр ярым диаметрлы зур белен дә пешергәннәр-ул Россия рекордлар китабына кертелгән. Киләчәктә монда тизлек рекордларын да яңартырлар, мөгаен. Хәзер Мамадыш үзәгендә ясалма таудан төшүнең уртача тизлеге – сәгатенә 25 (!) км. Катнашучылар боз трассасын хәтта күз алдына китереп булмаслык корылмаларга утырып, театрлаштырылган тамашалар күрсәтеп уза.

Дөньяны онытып ял итәр, үзеңне балачакка кайткандай тояр өчен менә дигән урын!

КИҢӘШЛӘР:

Әгәр сез SunnyFest фестивалендә көне буе бәйрәм итәргә ниятлисез икән, җылырак киенегез, аяк та өшерлек булмасын. Хәер, җирле кафе-ашханәләргә кереп җылынып чыгарга була, әлбәттә. Тамак ялгыйм дисәгез, бәяләре дә бик кыйммәт түгел.
SunnyFest креатив чаналар фестивален уздыру урыны үзгәрми: Мамадыш шәһәре, Совет урамы. Ә менә аның башлану көнен һәм вакытын бәйрәмнең сайтында алдан ачыклау зарур.
Керү ирекле. Катнашырга теләүчеләр өчен ике шартның гына үтәлүе кирәк: алар 18 яшьтән өлкәнрәк һәм үзләре ясаган чаналарда булырга тиеш.

НИЧЕК БАРЫРГА:

Автомобильдә. Казаннан Мамадышка М 7 трассасы белән 1,5–2 сәгатьтә барып җитәргә була, Чаллыдан килсәгез, юлга 40–50 минут китә.

«БӨЕК БОЛГАР» УРТА ГАСЫР СУГЫШЛАРЫ ФЕСТИВАЛЕ

Уздыру урыны: Болгар музей-тыюлыгы
Вакыты: 2021 елның 14–15 августы

Хәрби алышлар Болгар каласының урта гасырларда төзелгән борынгы диварлары янында оештырыла. Россия һәм чит илләрнең иң яхшы рыцарь-реконструкторлары биредә чын-чынлап сугыша, кораллары гына очланмаган, үткенләнмәгән. Тамаша һәм заманча интерактив чаралар бергә бара. Сугышларны карадыгызмы? Шунда ук көбәләрне киеп, аларның авырлыгын тоя аласың, махсус мәйданчыкта кылыч тотарга өйрәнеп була! Тәмле эль сырасыннан авыз иттеңме? Аны ничек әзерләү-кайнату хакында осталык дәресен дә үтәргә мөмкин. Тамашаның мәҗбүри өлеше – фолк-коллективлар белән дәртле тамашачылар башкаруында урта гасыр музыкасы һәм биюләр. Бар гаилә ялы мәйданчыгында иң нәни кунаклар өчен күңел ачу чаралары каралган. Кәефне тагын да күтәреп җибәрә торган бонус – музей-тыюлыкның архитектура хәзинәләрен карап чыгу мөмкинлеге.

КИҢӘШЛӘР:

Әгәр сез фестиваль дәвамында Болгарда калырга җыенасыз икән, кунакханәдә номерны алдан броньлагыз. Кемпингта палатка кору мөмкинлеге дә каралган (бер тәүлеккә 300–400 сум*), палаткалар өчен мәйданчык янәшәдә генә. Лагерьда урынны оештыручылардан алдан ук броньлап куярга кирәк. Болгарда сатып алган очракта,билетларның якынча бәяләре: өлкәннәр билеты– 400 сум, балалар өчен– 200 сум.**

НИЧЕК БАРЫРГА:

Автомобильдә. Казаннан Болгарга кадәр юл (200 км чамасы) 2,5 сәгатьтән 3 сәгатькә кадәр вакыт алачак.

**, ** – фестивальгә2019 елда керу хаклары. Пандемия сәбәпле, 2020 елда керу ирекле булган.*

«ТУГАН АВЫЛЫМ»: МИЛЛИ ӨСЛҮП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

«Туган авылыма» кергән җирдә кунакларны беренче булып... өчпочмакка һәйкәл каршы ала. Өчпочмак – татарларда иң киң таралган милли ризыклардан берсе, ул русларның кәбестә ашы кебек үк этник гармония һәм үзенчәлек символы булып тора. Татарларның бер генә бәйрәм табыны да өчпочмаксыз үтми.

Таш сукмаклар янындагы пөхтә бура йортлар Казанның нәкъ үзәгендәге пейзажны ачык һавадагы этнография музеена әйләндерә дә куя. Биредә уңайлы, тыныч һәм тәмле ризык исе килә... «Туган авылым» милли комплексында гүя үткәннәр тарихта калмаган, ә бүгенге көн белән янәшә атлый. Хәтта модернистик корылмалар белән әйләндереп алынган архитектура ансамбле, концептуаль яктан үзара капма-каршы булса да, алар белән бәхәскә керми. Киресенчә, заманча шәһәрнең мәдәни үзәгендә урнашкан үзенә бер төрле авыл-театр дигән тойгы кала.

КАЗАН – КУНАКЧЫЛ ШӘҺӘР

– Бу турыда безнең милли комплекска килгән һәрбер кунак әйтә диярлек, – дип сөйли «Туган авылым»ның туристик юнәлеш җитәкчесе Фәридә Бибарс. – Без һәрвакытта да аларны бәяләмәләр калдыра торган урында каршы алабыз һәм озатып калабыз. Һәм барысы да диярлек Казанда аларны ничек итеп колач җәеп каршы алулары турында ассызыклап әйтә. Минемчә, ачык йөз – безнең милли комлпекс өчен дә мөһим сыйфат. Ә кунакчыллык – туризмның йөзе.

Биредә һәркем үзенең күңеленә якын шөгыль таба ала, чөнки «Туган авылым» территориясендә мәчет, «Тегермән» мәдәният-һөнәрчелек үзәге, сувенирлар кибетләре, һөнәрләр келәте, «Аю йорты» йомшак уенчыклар музее, «Татар мунчасы» комплексы, «Exit Games» гаиләуеннар үзәге, Никах үзәге бар. Ял итү һәм күңел ачу өчен мөмкинлекләр зур, бәяләре дә кесәгә сугарлык түгел. Биредә балаларга да, олыларга да күңелле.

Мөгаен, «Туган авылым» – Казанда архитектурасын, һөнәр һәм традицияләрен күреп белеп, шулай ук татар милли ризыкларын авыз итеп карап, чын татар мохитенә чуму мөмкинлеге булган туристик үзәкләрнең берседер.

Фотолар «Туган авылым»нан алынды. Реклама.

«Туган Авылым»да ел саен рекорд! Иң зур тутырма, чәкчәк, пәрәмәч, талкыш каләвә... Быел нәрсә булыр, әлегә билгесез. Әмма монда шаккатырырга ияләшкәннәр. Көтәбез!

ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Бүген туристларны җиде ят ризык белән шаккатыру мөмкин түгел. Киресенчә, безнең белән йөзләрчә еллар янәшә «атлаган» ризыклар чын мәгънәсендә экзотикага әверелә. Гади, тәмле һәм чиста ризык. «Туган авылым» кунакларының иң яратканы – әле генә утлы күмердә чыжылдатып пешереп алган мич коймагы. Үзенә бер рецепт буенча пешкән коймакны ашарга шәһәрнең төрле почмакларыннан киләләр. Кунакларның да барысы да диярлек, теленңе йотарлык дип, мактый-мактый авыз итә. Биредә сезне татарның милли ризыклары гына түгел, ә вегетарианнар өчен өчпочмаклар, дөрес туклану десертлары белән дә шаккатыралар әле.

Әйе-әйе! «Туган авылым»да кунакларның һәрбер теләген үтәргә әзер торалар. Итсез өчпочмак кирәкме? Ә нишләп булмасын? Әйтергә кирәк, катнаш сугыш сәнгате буенча дүрт тапкыр дөнья чемпионы Федор Емельяненко әле күптән түгел генә милли комплексның кысыр менюсыннан канәгать калган. Эстраданың популяр җырчысы Стас Михайлов «Туган авылым»ның Пекинча үрдәген бик яратып ашаган.

Милли комплексны оештыручыларның берсе Радик Абдрахманов фикеренчә, моның сере аш-су осталарының уңганлыгында һәм, әлбәттә инде, азык-төлекнең сыйфатында:

– Безнең дуслар-кунаклар кабат-кабат килсен, дибез икән, сервис һәм ризыкларга сүз тидерерлек булмасын. Шуңа да без азык-төлекне ышанычлы фермерлардан гына сатып алабыз. Безнең менеджерлар, кондитерлар, аш-су осталары командасы исә иҗат итәргә һәм шаккатырырга һәрвакыт әзер.

РАДИК АБДРАХМАНОВТАН КИҢӘШ:

– Безнең милли комплекска килгәч, татар халык ашларын тулаем ача алырдай ризык сайлагыз. Зур бәлешне ашап карарга киңәш итәм. Биредә аны бик тәмле пешерәләр.

ФӘРИДӘ БИБАРСТАН КИҢӘШ:

– Әйбәт ял итәр һәм нindидер яңа урын ачар өчен меңнәрчә чакрым читкә китәргә кирәкме. «Туган авылыма» барып карау да җитә. Бирегә берничә сәгатькә генә килгәндә дә, беркайда да булмаган уникаль мохиткә чумарга була. Моның өчен вакыт сарыф итәргә кирәкме? Әлбәттә! Уңай тәэссоратлар калачакмы? Һичшиксез! Милли комплексның парковкасы зур. Урын һәркемгә җитә!

ЧЫН ТАТАР МОХИТЕНДӘ

Чыннан да, «Туган авылым» командасы яулап алган статусын елдан-ел саклап килә, казанышларын яңартып тора һәм сервисны кунакларның теләгән алдан күреп оештыра.

Ресторан тәрәзәләреннән күпер һәм яшел чирәмлектә үсеп утырган чәчәкләр күренеп тора. Барысы да кечкенә һәм матур. Ресторан эчендә үзеңне авыл өе эчендәге кебек тоясың. Хәтта пәрдәләр дә төрле төстә, савыт-сабаларга исә дизайнерлар татарның милли бизәкләрен төшергән. Бөтен җирдә милли бизәкләр. Мич янындагы пәрдә менә-менә ачылып китәр дә, аның артыннан табагачына таба утыртып әбекәй килеп чыгар кебек. Ә табада – кайнар пар бөркеп торган зур бәлеш.

«Туган авылыма» республика кунаклары гына килми, Татарстанда яшәүчеләр үзләре дә теләп йөри: тәмле ашарга гына түгел, ә кабатланмас чын татар мохитенә күмелергә. Өйгә кайтышлый кичке аш ашап чыгарга милли комплекска юнәлүең үзе ни тора. Ә башкала кунаклары аны һич икеләнмичә сәяхәт маршрутына кертә ала.

ВАКЫЙГАЛАР

«Туган авылым» үз кунакларының бирегә дусларына кунакка килгән кебек яратып йөрүләрен тели. Шуңа да проект һәрдаим үсештә. Июнь аенда монда республиканың халык артисты Әлфия Авзалованың музеен ачу планлаштырыла. Биредә татар эстрадасы йолдызлары белән иҗади кичәләр үтәчәк, музыка яңгыраячак, кунакларны безнең милли музыкаль мәдәният белән таныштырачаклар. Шулай ук халкыбызның яраткан җырчысы рецепты буенча пешерелгән пәрәмәч белән сыйлаячаклар.

Быел шулай ук ел саен үтә торган «Балачак» халыкара балалар вокаль фестивале үз эшен дәвам иттерәчәк. Ул «Туган авылым» милли комплексының «Игелек янәшә» дигән хәйрия фонды базасында оештырыла. Бүләкләр, йолдыз белән клипта төшүләр... Балалар иҗаты – җитди эш.

Быел программага «Туган авылым» милли комплексы территориясе буйлап «Фонарьчы» интерактив экскурсиясе белән иммерсив квест-променад өстәлә.

«Туган авылым» милли комплексының адресы: ТР, Казан шәһәре, Туфан Миңнуллин урамы, 14/56 йорт
Элемтә өчен: +7 (843) 202-21-94
+7 (937) 281-48-76
www.tugan-avilim.ru

АврорА

***«Аврора»** шифаханәсе Сочи шәһәренең Лазарев районында урнашкан. Ул яхшы ял итәргә, шулай ук медицина һәм сәламәтләндерү программалары комплексын узарга теләгән һәркемне сөенеп каршы алачак.*

354226, Краснодар крае, Сочи шәһәре, Лазарев районы, Аврора ур., 6

Бронь хезмәтенең эш сәгатьләре: дүш-якш 08:00 сәгатьтән 19:00 сәгатькә кадәр

Бронь хезмәте телефоннары: +7 862 274-61-11, +7 918 605-48-43
Факс: +7 862 274-61-08
Россиядән бушлай шалтырату: 8 800 444 30 73

bron@avrorasochi.com
avrora6111@yandex.ru

www.avrorasochi.com

Фото «Аврора» шифаханәсе тарафыннан бирелде. Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ТАТАРСТАН БУЙЛАП АВТОМОБИЛЬДӘ!

Татарстанга кайсы кыйтгадан гына килеп керсәгез дә, сокланырлык урыннар табарсыз! Төньякта да, көньякта да, көнбатышта да, көнчыгышта да карарлык, күрсәтерлек әйберләребез бар. Башка бер җирдә дә карап булмый торган җанлы тарих! Башка бер җирдә дә ишетеп булмый торган риваятьләр! Башка бер җирдә дә кабатланмый торган матурлыклар! Татарстанда гына булган уникаль урыннар янында төшкән фотосурәтләр! Гаиләгез белән автомобильгә төялегез дә онытылмаслык тәэссоратлар артыннан маҗаралы сәяхәткә чыгыгыз!

ЗӨЯ УТРАУ-ШӘҺӘРЕНӘ –
чиркәүдәге фрескаларга сокланырга, утрау ярларын юучы Идел, Чуртан һәм Зөя елгаларының мул суына карап хозурланырга...

ЯР ЧАЛЛЫГА –
легендар КАМАЗлар ватанын күрергә, ни өчен шәһәр кайчандыр СССР генераль секретаре булган Брежнев исемен йөрткәнен белергә, Высоцкий музеенда булырга, «Түбәтәй» түбәсенә менәргә...

ТҮБӘН КАМАГА –
Россиядә иң биек мәчет манарасын, ике көпчәкле транспорт дөньясы раритетларын күрергә, Энтузиастлар бульварында сәйран кылып, Советлар Союзының төрле почмакларыннан җыелган әлеге энтузиастларның ничек итеп япан кырда кала төзүләре турында ишетергә...

ТӘТЕШКӘ –
400 басмадан торган иң текә баскычтан күтәрелергә, Балыкчылык тарихы музеена керергә, кырпы балыгы һәйкәле янында фотога төшәргә, Долгая Полянадагы Молостововлар утарында сәйран кылырга...

PRESSA

ТАТАРСТАН БУЕНЧА АВТОСӘЯХӘТЛӘР

КАРТА

Республиканың иң мөһим истәлекле урыннарына ничек барырга һәм бер көн эчендә Зөя, Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама һәм Тәтештә нәрсәләрне карарга мөмкин.



Мәскәү, Түбән Новгород өлкәсе, Мари Эл Республикасы ягыннан

Ульяновск, Самара, Оренбург өлкәләре ягыннан


МЕНДЕЛЕЕВСК
АЛАБУГА
ЯР ЧАЛЛЫ
МАМАДЫШ
МИНЗӘЛӘ
АКТАНЫШ
ТҮБӘН КАМА
МӨСЛИМ
ЗӘЙ
САРМАН
ЯҢА ЧИШМӘ
ӘЛМӘТ
АЗНАКАЙ
ЧИРМЕШӘН
УРЫССУ
ЛЕНИНОГОРСК
БӨГЕЛМӘ
БАУЛЫ
Киров өлкәсе ягыннан
Башкортостан Республикасы һәм Удмуртия Республикасы ягыннан

Автосәяхәт. Зөя

1

2

3

1

Зөянең иң истәлекле урыннарыннан берсе – Успение монастыре комплексы, аның Успение соборы ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән. Монастырьда изге Христофор Псеглавец сурәте төшерелгән уникаль фреска саклана (XVI гасыр).

2

Зөя шәһәре язмышы экияткә охшаган, анда бер үк вакытта матур да, куркыныч та сәхифәләр бар. Бу турыда Утрау тарихы музеенда сөйләрләр.

3

Имештер, Явыз Иван, Казанга яу белән баруының уңышлы тәмамлануын сорап, нәкъ менә Троица чиркәвендә гыйбадәт кылган, диләр. Чиркәү XVI гасырдан сакланып калган һәм Иоанн Предтеча Зөя монастыре территориясендә урнашкан.

4

Риваять буенча, 1920 нче елларда Раштуа мәйданына Троцкий фәрманы буенча Иудага һәйкәл куелган. Бүген мәйдан янәшәсендә Торжок урнашкан, анда тәмле итеп ашап чыгарга һәм күңелгә ошаган сувенирлар алырга була.

5

Каланчадан (Зөя сәнгать галереясы аша керергә) утрауга, аны уратып алган Идел, Чуртан һәм Зөя елгаларына искиткеч гүзәл манзара ачыла.

6

«Татар бистәсе» Агач археологиясе музеена кергәч, сез агач йортлар кварталына килеп эләгәсез. XVI–XVIII гасырларда төзелгән корылма калдыклары бүген дә шунда тора: алар шунда табылган һәм ләмнән чистартылган гына.

НӘРСӘ АВЫЗ ИТӘРГӘ:
Зөядә һичшиксез татып каралырга тиешле ризыклардан берсе – «Трактир»да икмәк эченә салып бирелә торган борщ. Шулай ук утрауда телеңне йотарлык тәмле хачапури пешерәләр.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:
Кунакханәләрдә. Ике кешелек номер тәүлегенә 2500 сумнан башлана.

4


5

6

АВТОСӘЯХӘТ. КАЗАН





1

Казан Кремле – шәһәрнең тарихи үзәге. Борынгы ныгытма территориясендә сез ак мәрмәрдән төзелгән Кол Шәриф мәчетен, 500 еллык Благовещение соборын, Казан ханнары төрбәсен, бер якка авыша барган Сөембикә манарасын, бик күп музейлар һәм матур фотолар өчен менә дигән урыннар табарсыз.

2

Иске Татар бистәсендә сез йөз ел элек шәһәрдә яшәгән татарларның – сәүдәгәрләр, галимнәр, дин әһелләре, шагыйрьләр һәм актерларның тормыш-көнкүреше белән таныша аласыз.

3

Җәяүлеләр генә йөри торган Бауман урамында кызыклы арт-объектлар, күзәтү мәйданчыгы булган Богоявление чиркәү манарасы һәм үзенчәлекле дә, матур да сувенирлары булган бик күп кибет урнашкан.

4

Кремль яр буеннан төнге Казанга иң матур манзараларның берсе ачыла.

5

Шәһәр үзәгеннән нибары 10 чакрымда гына салкынча һәм үтә күренмәле Зәңгәр күлләрнең зәңгәр касәсенә чумарга була.

НӘРСӘДӘН АВЫЗ ИТӘРГӘ:

Казан үзәгендә телеңне йотарлык тәмле милли аш-су әзерли торган кафе-рестораннар бихисап. Тавык итеннән токмачлы аш, казылык, кыстыбый, өчпочмак, гөбәдия, чәкчәк, талкыш кәләвә – бу ризыкларны бер авыз итеп карагач, сез инде аларның исемнәрен беркайчан да онытмаячаксыз.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:

Казанда куну өчен җаның ниндине тели, шундый урынны табарга була. Биредә дөньякүләм таралган брендларның отельләре дә (6000 сумнан башлап), җирле отельләр дә (3000 сумнан), шул исәптән хәләл стандартларына туры килә торганнары да (5400 сумнан), хостеллар (1000 сумнан), шәһәрнең төрле урыннарындагы апартаментлар (1400 сумнан) да бар*.

** Ике кешелек номерда бер тәүлек куну бәясе.*

АВТОСӘЯХӘТ. ЯР ЧАЛЛЫ





1

«2.18» бизнес-үзәге – шәһәрнең визит карточкасы. Үзенең адресы буенча шулай аталган – 2 нче комплекс, 18 нче йорт. Икенче атамасы – «Түбәтәй». Хәзер биредә 25 катлы бизнес-үзәк урнашкан. Түбәсендә – күзәтү мәйданчыгы. Бинага – 50 ел.

2

1960 нчы елларда Кама елгасында төзелгән Түбән Кама гидроэлектростанциясе. Кама каскадындагы соңгы станция. Югарырак Воткинск ГЭСы (Чайковский шәһәре) һәм Кама ГЭСы (Пермь шәһәре) урнашкан.

3

«Тәүбә» мәчетен 1989 елда сала башлыйлар, ул Идел буе Болгар-станында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана. Бина, шул исәптән, хәйриячеләр акчасына да төзелгән.

4

1974 елның җәендә Владимир Высоцкий Автоград төзүчеләренә концертлар куя. Бард «Кама» кунакханәсендә яши. Кунакханә янәшәсендәге мәйдан аның исемен йөртә, ә үзәктә Высоцкий хөрмәтенә гитара-чаң һәйкәле куелган.

5

Табиев яр буенда 8 метрлы хәрефләрдән «Яр Чаллы» дип язылган, яшь парлар өчен фотозона бар. Яр буенда велосипед, ролик, скейтларны прокатка алып торырга була, шулай ук бик күп кафе эшли.

6

«Ватан-ана» скульптурасы – ГЭС бистәсенең 9 нчы комплексында урнашкан мемориаль комплексның бер өлеше. Монумент утта янып, көлдән кабат терелгән Феникс кошын гәүдәләндерә, аның канатларында Бөек Ватан сугышы каһарманнарының йөзләре сурәтләнгән. Бу рәссам, архитектор, Казандагы Галәм гыйбадәтханәсен төзүче Илдар Хановның беренче иҗат эшләреннән берсе.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:

Иң арзанлы кунып чыгу урыны – хостелда (900 сум), иң кыйммәтлесе – шәһәр үзәгендә өч йокы бүлмәсе булган апартаментлар (7000 сум)*.

** Ике кешелек номерда бер тәүлек куну бәясе.*



АВТОСӘЯХӘТ. ТҮБӘН КАМА

1

2

3

1

Үзәк Җәмигъ мәчете – шәһәрдәге иң истәлекле урыннардан берсе. Дүрт почмактагы 66шар метр биеклектәге дүрт манарасы аны Россиядә иң биек мәчетләрдән берсе итә.

2

Риваять буенча, борын заманда Кызыл Чишмәдә Әсмагыйҗан имам яшәгән. Ул сихәтле чишмәдә коену өчен бассейн һәм мәгарә ясаган. Әлеге изге чишмә дә, аның турында бик күп риваятьләр дә бүгенгә кадәр яши.

3

Велосипедлар музеенда сез «педальле ат» һәм ике тәгәрмәчле транспорт дөньясындагы башка раритетларны күрә аласыз, мәсәлән, беренче велосипедларның берсен, Швейцариядән үк кайтартылган хәрби велосипедны, цирк Пенни-фартингын һәм башкаларны.

4

Тукай паркының икенче исеме – «Уку һәм ял паркы». Ямьле аллеяларне Тукай әсәрләреннән персонажлар бизи, ә репродукторлардан аның әкиятләрен тыңларга була.

5

«Манзара» күзәтү тәгәрмәченнән шәһәргә гүзәл манзара ачыла.

6

Түбән Кама, яшь шәһәр булса да, үзенең 60 еллыгын бәйрәм иткән инде. Шәһәр музеенда сез аның ничек төзелә башлавы, берничә ел эчендә бөтен илдән җыелган энтузиастларның ялан кырда ничек итеп шәһәр төзеп куюы турында белә аласыз.

НӘРСӘ АВЫЗ ИТӘРГӘ:

Түбән Кама төзелешенә бөтен Советлар Союзыннан килгәннәр. Бик күпләр өчен ул туган йортка әйләнгән. Шунлыктан монда төрле милләт халыкларының иң тәмле ризыклары белән сыйлану мөмкинлеге бирә торган кафе һәм рестораннар күп.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:

Түбән Кама – кунакчыл шәһәр. Монда арзан гына хакка хостелда (1100 сумнан), кунакханәдә (3500 сумнан) яки апартаментларда (1400 сумнан) кунып чыгарга була.*.

** Ике кешелек номерга бер тәүлеккә урнашканда.*


4

5

6

1


2

3



1

Тәтеш пристаненнан шәһәргә менә торган баскычтан Идел елгасына искиткеч гүзәл манзара ачыла. Бу баскыч – Идел елгасында иң озыны һәм иң текәсе. Ул 400 басмадан тора.

2

Туган якны өйрәнүче, тикшеренүче, Лев Толстойга әсәрләрен редакцияләргә ярдәм иткән Елизавета Молоствова яшәгән һәм эшләгән утар. Молоствовлар утары Долгая Поляна табигать паркында урнашкан. Ул архитектура һәйкәле һәм... аномаль активлык урыны.

3

Балыкчылык тарихы музее, әлбәттә, балыкка багышланган.

4

Нәкъ менә Тәтештә сез кырпы балыгына гаять зур һәйкәл күрерсез. Бу очраклы түгел. 1921 елда балыкчылар Тәтеш янында тота аны. Әлеге гаҗәеп балыкның авырлыгы – 960 килограмм, озынлыгы 5 метр булган. Уылдыгы гына да 16 пот чыккан.

5

Сәүдәгәр Серебряков йортында Тәтеш төбәге тарихы музее урнашкан. Ул классик туризмны яратучылар өчен кызыклы булачак.

НӘРСӘ АВЫЗ ИТӘРГӘ:

Идел балыгыннан пешкән уха. Биредә аны үзләре генә белгәнчә, учакта пешерәләр. Шулай ук биредә балыкны төрлечә әзерлиләр: ыслыйлар, каклыйлар, киптерәләр. Тәтеш күмәчләре белән төрле эчемлекләр һәм үлән чәйләре дә тәмле булачак. Тәтештә бал сатып алырга да онытмагыз.

КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:

Автойортта сәяхәт итүчеләр стендка ату мәктәбе янында туктый ала. Туктап тору бәясе – тәүлегенә 700 сум. Электр уты кертелгән, суы, биобәдрәфләре бар.

4

5



ЯШЕЛ ҮЗӘН РАЙОНЫ: «КҮРЕП КАЙТУ МӘҖБҮРИ!»

Татарстанның Яшел Үзән районында «Күреп кайту мәҗбүри!» дип картада билгеләп куярлык урыннар бик күп. Шуларның өчесе турында – безнең юлкүрсәткечебездә.

РАИФА ИЗГЕ АНА МОНАСТЫРЕ

Ирләр монастыреның мәһабәт храмнары төз-төз наратлар урап алган гаҗәеп матур урында – Раифа күле яр буенда урнашкан. Әлеге гыйбадәтханәләрне инкыйлаб давылларына кадәр алар нинди булган, шул килеш күрә аласыз – монастырь комплексы тулысынча сакланган. Дин белән дистәләрчә еллар көрәшкән дәүләт өчен бик-бик сирәк очрак бу.

Монастырь тарихы 1613 елдан башлана, шул чакта Филарет исемле дәрвиш монах урмандагы аулак җиргә барып урнаша. Вакытлар узу белән, монда акрынлап монастырь барлыкка килә.Аңа исем Синай тавыннан ерак түгел Раифа чүлендә мәҗүсиләр тарафыннан үтерелгән монахлар хөрмәтенә бирелә.

Монастырьның үткәнендә фаҗигале сәхифәләр шактый. Революциядән соң аны ябып куялар, ә монахлар атып үтерелә. Монахлар яшәгән хөҗрәләрдә сәяси тоткыннар өчен төрмә, аннары кече яшьтәге җинаятьчеләр өчен колония булдырыла. 1990 нчы елларда монастырьга яңадан җан өрелә, хәзер биредә 30 га якын послушник монахлыкка әзерләнә, гыйбадәтханәләрдә келәүләр башкарыла. Раифаның иң мөкатдәс әйбере – Могҗизалар тудыручы Грузин Изге Ана иконасы.

Монастырь храмнарында еш кына танылган шәхесләрне күрергә мөмкин. Раифа монастырена Борис Ельцин, Алла Пугачева, Евгений Леонов, Юрий Шевчукның килгәне бар.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан Яшел Үзәнгә таба юл белән Раифа борылышына кадәр. Ераклыгы – 30 км.

ИДЕЛ-КАМА ТЫЮЛЫГЫ ДЕНДРАРИЕ

Сез планетабызның төрле почмакларына фантастик сәяхәт ясый аласыз. Тыюлыклы Раифа урманы уртасындагы егерме ике гектар мәйданда 530 дан артык төр агач һәм куак үсә, чәчәк ата һәм җимеш бирә. Агачкуаклар Америка, Европа һәм Азиядән кайтартылган.

Аларның күбесен башка урында, бәлки, күрмәссез дә: дендрарий– сирәк очрый һәм юкка чыгып бара торган үсемлек төрләрен үрчетү урыны. Бер үк вакытта ул экзотик төрләрнең безнең шартларда үсү мөмкинлеген тикшерә торган полигон вазыйфасын да башкара.

Монда сез нәфис япон сакурасы белән ләззәтләнә аласыз. Ябалдашлары әллә кайда югарыда кушылган агачларның шомырт икәнен белеп гаҗәпкә калырсыз, дөрес, гади шомырт түгел ул, ә Ерак Көнчыгыш кунагы – Маака шомырты. Американың Бөек күлләре янында үскән көнбатыш туясының хуш исен дә тоя аласыз, – бу агач әрәмәлегендә һиндиләр вигвамнарын кора торган булган.

Дендрарийда кайсы агачны гына алсаң да– чын ачыш. Ә тирә-юньдә– кеше кулы тимәгән, беркайчан да киселмәгән урман. Кайбер борынгы наратларның яше 270 кә җитә.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан Яшел Үзәнгә таба трассадан Раифа чатына кадәр, аннары – тыюлык урманы аша юлдан Садовый бистәсенә кадәр.

«ТАТАР АВЫЛЫ» ЭТНОГРАФИЯ МУЗЕЕ

Вакыт җилләре каралткан буралар, авыл юлларында йөреп таушалган арбалар, борынгы җиһазлар... Гүя хуҗалар моннан әле генә китеп барган. Ә моңарчы исә арбасын-чанасын төзәткәннәр, бишек тирбәткәннәр,тимерче алачыгында эшләгәннәр.

Ачык һавадагы «Татар авылы» этнография музеенда һәрнәрсә – чын, тарихи әйбер. Кара мунчада – диварга тәмам сыланып каткан корым һәм бүрәнәләргә сеңгән төтен исе. Иске тегермән ташларында – онта. Агач йортта исә – авызының өстенә кара корым сарылган, әле яңа гына суынып килгән мич.

Барлык бу байлыкны күзәтеп йөрү генә түгел, кул белән тотып карарга да була. Борынгы кабаны да, киез итек басу өчен калыпларны да. Һәм хәтта гигант тегермәннең (сүз уңаеннан, ул тегермән эшли дә әле) түбә астында урын алган,өстәвенә агачтан ясалган әкәмәт зур тешле тәгәрмәчләрне дә тотып карый аласыз. Кулың белән кагылуга, әйтерсең, ата-бабаларыбызның гасырлар буена тупланган энергетикасы сиңа күчеп, куәт өсти.

Ә өйләр арасындагы үләндә тавыклар чемченә, гаярь казлар исә ишегалдына керер капка төбен саклый. Утарда – сарыклар һәм кәҗәләр... Барысы да йөз ел элекке гап-гади татар авылындагы кебек.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Казаннан М7 трассасы белән Мәскәүгә таба юл тотып, Исәк авылына кадәр.

Фотолар Татарстан Республикасының Яшел Үзән районыннан алынды. Реклама.

ИМИНЛЕГЕҢ

ҺӘРВАКЫТ СИНЕҢ ЯНДА

Фатирны сакларга кирәклеге һәркемгә билгеле. Заманнар никадәр генә тыныч тоелмасын, караклар һәм талаучылар һәрвакыт табылып тора.

Муенсалар, алка-беләзекләр, йөзекләр, отпусктан калган берничә йөз доллар, бижутерия, ун тәңкәлекләр җыелган савыт, берничә шешә аракышәраб, мәче азыгы, Икеадан алынган келәм– бу исемлекне карак корбаны булган бер кыз Интернетта язып чыккан. Аны йога-ретритта вакытта таларга өлгергәннәр. Постына аңлатма биргәндә, автор урланган әйберләрнең гомум хакының, үз йортының инде куркынычсыз түгеллеге турында хис белән чагыштырганда, чүп кенә икәнен белдерә.

Интернетта каракларның ничек фатирга үтеп керүләре турында бик күп гыйбрәтле бәяннар бар. Алардан шун-

Фотолар «ТЕКО» компаниясеннән алынды. Реклама.

дый нәтиҗә ясарга мөмкин: мәкерле осталарны берни дә туктатмаячак. Теләсә нинди йозакны да, әллә нинди серле ишекләрне дә ачып була. Шуны истә тоту зарур: карак байлар йортына гына керә дип уйлау дөрес түгел. Мәкерле максатлары өчен алар еш кына шәһәр фатирларын сайлый. Іоракның иминлеген кайгырту өчен хәзер иң кулай вакыт, чөнки алда – җәйге яллар фасылы.

Бу – бөтен гаилә белән бергә кояш нурларында ләззәтләнә торган вакыт кына түгел, йортыгызның бер караучысыз калган чагы да.

Үз милкеңне чакырылмаган кунаклардан ничек сакларга?

«Камера урнаштырыгыз, һәм барысы да күренеп торачак!» – социаль челтәрләрдән файдаланучылар кулга алынган бер каракның әнә шундый сүзләрен үрнәк итеп китерә. Тик өйдән еракта вакытта, фатирыгызга караклар кергәнен күргәч нишләргә соң? Иң камил ысул – махсус сак комплексын урнаштыру, аның җайланмалары сезгә видео җибәреп кенә калмый, сак хезмәтенә дә хәбәр итә.

Видеокамералы Security Hub комплекты.

Цифрлы куркынычсызлык системалары базарындагы иң оптималь чараларның берсе – Security Hub* комплекты.

Комплектка контроллер, хәрәкәт датчигы, ишек һәм тәрәзәләр ачылу/ябылу датчигы һәм видеокамера керә. Системаны урнаштыру интерьер дизайнын бозар дип борчылмаска да мөмкин. Security Hub датчиклары чыбыксыз, аларны теләсә кайсы бинада бик уңайлы шәкелдә урнаштырып була. Барлык җайланмалар да мөмкин кадәр оптимальләштерелгән. Хәрәкәт датчигы массасы 20 килограммнан артык объектларны сизә, камера тирә-як манзараны



1 бүлмәле фатирны чит кешеләр керүдән, янгын һәм аварияләрдән саклау өчен чыбыксыз сигнализация. Сигнализацияне көйләү һәм аның белән идарә итү (кушу/сүндерү) милекче смартфонындагы «Security Hub» мобиль кушымтасы аша башкарыла, радиоканаллы брелоклар аша идарә итү мөмкинлеге дә бар. Чыбыксыз датчикларның берсе хәвеф турында хәбәр итеп кушылганда (хәрәкәт аркасында, ишек ачылу, төтенләү, су агу очрагында), Security Hub контроллеры вакыйганы шул мизгелдә теркәп, мәгълүматны кулланучы смартфонына тапшыра.



Система белән мобиль кушымта ярдәмендә идарә итү.

хәтта караңгыда да «күрә» һәм видеосурәтне хуҗага тапшыра.

Комплекс читтән торып идарә ителә. Моның өчен смартфонга Security Hub кушымтасы куела. Аның ярдәмендә сигнализацияне сак режимыннан аерырга яки кушарга була. Сигнализациянең көтелмәгән кушылуы турында кулланучыга push-хәбәр, тавышлы һәм сүзле хәбәр килә, аның тавышы шактый куәтле – ишетми калу мөмкин түгел. Тревога сигналы шулай ук Росгвардия яки шәхси сак предприятиесе** бүлекчәләренең үзәкләшкән күзәтү пультына да тапшырыла.

Система физик йогынтыдан һәм хакерлык һөҗүменнән яхшы сакланган. Контроллер смартфоныгыз белән йорттагы интернет ярдәмендә яки аерым сим-карта аша элемтә тотачак.

Security Hub комплексының эше куркынычсызлык функциясе белән генә чикләнми. Башка датчиклар белән туләндырылган система «акыллы йорт» режимында эшләргә сәләтле: хәрәкәт вакытында утны кушу; үсемлекләргә су сибү; капка ачу-ябу; су бәреп чыгу датчигы эшләгән очракта краннарны ябып кую; фатирның сак режимын кушканда, электр утын һәм розеткаларны сүндерү һәм башкалар.

Системаның сыйфаты һәм дәрәҗәсе аңа сорау зур булу белән раслана, өстәвенә, чит илләрдә дә. Әлеге продуктны җитештерә торган ширкәт – Татарстанның ТЕКО компаниясе (1992 елдан бирле сак системалары эшләп чыгару белән мәшгуль) 2021 елда «Ел экспортеры» премиясе лауреаты булды.

Компания Security Hub комплексы белән БДБ, Латин Америкасы, Якын Көнчыгыш һәм Азия – Тын океан төбәге илләрен тәэмин итә.

– Бу продуктның ап-ачык өстенлекләреннән – көндәшлеккә сәләтле бәя, «акыллы йорт» функцияләре, бишьеллык гарантия чоры, «болытлы» серверлардан түләүсез файдалану мөмкинлеге, системаны урнаштыру һәм көйләүнең гади һәм тиз башкарылуы. Җиһазлар «Охрана» фәнни-тикшеренү үзәгенең техник чаралары исемлегенә кертелгән һәм полиция, ведомстводан тыш сак бүлекчәләре, шулай ук шәхси сак предприятиеләре тарафыннан сак эшендә кулланыла, – ди «Теко-Торговый дом» ҖЧҖнең актив сату төркеме җитәкчесе Андрей Городилов. – Security Hub инде 4 ел чыгарыла һәм, сак системаларын сайлау мөмкинлегенең зурлыгына карамастан, базарда алдынгы продуктларның берсе булып кала бирә.

ТЕКО

«ТЕКО-ТД» ҖЧҖ
420138, Казан шәһәре, Җиңү пр., 19
+7 (843) 528-03-69
sales@teko.biz
www.teko.biz
teko_astra

Контроллер һәм Security Hub датчиклары ярдәмендә көйләнә ала торган «акыллы йорт» функцияләре.

Security Hub – Секьюрити Хаб.*
*** Күрсәтелгән хезмәтләрдәге белгечләрнең консультациясе һәм килешү төзү таләп ителә.*

Язманың видеоварианты да бар

Автор: Руфия Фазылова

ТАҢ СУЫНЫҢ ШИФАСЫ

«Татарстан» журналы халкыбызның ата-бабадан килгән затлы һөнәрләрен, шөгыльләрен барлауны дәвам итә. Бу юлы дини эчтәлектәге традицияләрне барладык – таң суының шифасы турында сөйләштек. Әйе, әби-бабаларыбыз авыру-сырхауларны җиңеләйтү, күз тиюне бетерү өчен әнә шулай таң суын алып юынган. Ул бер йола булган. Күп авылларда бу эш инде онытылган, ә менә Арча районының Кышкар авылында таң суын әле бүген дә алалар икән.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

«ГАЗИЗ ЧИШМӘСЕ» СУКМАГЫНДА...

Фатыйма апа Төхфәтуллинага тиздән 85 яшь тула. Гомер буе туган авылында гомер кичергән ул. Бүген ялгызы яши. Тормыш аны шактый сынаса да, авырлыкларга бирешмәгән. Әле дә дүрт оя умарта тота. Иң гаҗәбе – ялгызы балны аерта, яңа күч аерылып чыкканда, аларны җыя.

– Үземне белгәннән бирле бал кортлары карыйм. Әнием байлар нәселеннән иде, шуңа күрә бездә гел бал кортлары булды, – ди әбекәй.

Фатыйма апа бик күп догалар белә. Барысын да әбисе, әнисе өйрәтеп калдырган. Шул исәптән таң суын алып, аңа дога кылып коенуны да.

Таң суын чәршәмбе алсаң яхшы икән.

– Ни өчен шулай? – дип сорыйм.

– Әбиләр шулай эшли иде, – дип җавап бирә Фатыйма апа.

Аңлашыла ки, таң суын кояш чыкканчы алалар. Әлбәттә, иң яхшысы чишмә суы. Тик бер дә булмаса, краннан алган су да ярый, иң мөһиме – таң атканчы булсын икән.

– Хәзер өйләргә дә чишмә суы килә инде, – ди Фатыйма апа.

Шулай да без шартын туры китерергә булдык – чишмә суына төштек. Дөрес, таң атканчы Кышкарга барып җитеп булмады, иртәнге тугыз иде.

Чишмә Фатыйма апаның әтисе исемен йөртә икән – «Газиз чишмәсе». Аны матурлап ясап куйганнар.

– Әтиегезнең бу чишмәгә нинди катнашы бар? – дип кызыксынам.

– Безнең нигезгә орынып торганга, халык чишмәгә шундый исем биргән, – ди әбекәй. – Әтием, Шәфигуллин Газиз Шәфигулла улы, 1942 елның 6 октябрендә Чечен-Ингуш Республикасының Малгобек шәһәрендә батырларча һәлак булган. Үскәч, без ул җирләрне әни белән барып карадык. Шунда Туганнар каберлегендә дога кылдык. Без әтидән алты бала калганбыз. Фронттан кара мөһерле хат алганда, әнигә утыз сигез яшь кенә була. Озак та үтми, унөч яшендәге апам да җан тәслим кыла. Абыйны сугышка алалар. Әни ничек түзде икән, дим. Бик дини иде ул, күрәсең, Аллаһыга ышану, таяну да көч биргәндер.

Фото: Лилиана Вәлитова

КЫЙБЛАГА КАРАП...

«Газиз чишмәсе»нең татлы суын авыз итеп, чиләкләргә су алып өйгә кердек. Әби алдан ук кисәтеп куйды:

– Таң суын бары тәһарәтле килеш кенә алырга кирәк.

Әлбәттә, чиләк тә ару булырга тиеш. Бу очракта без эшнең асылын аңлау өчен генә чишмәгә бардык, су алдык. Ә инде чынлап та таң суыннан шифа алырга теләгән кешеләр Фатыйма апа әйткәнчә эшләргә тиеш.

Фатыйма апабыз дәвам итте:

– Эш тәртибе болай, балалар. Чишмәдән су алганда ук кыйблага карап: «Илаһи ният кылдым, фәлән кешенең авыртуына шифа булсын», – дип, ният әйтү шарт. Һәм чишмәдән кырык бер чүмеч су алып чиләккә саласың. Чүмеч белән су алган саен: «Бисмиллаһир-рахмәәнир-рахиим, фәлән, фәләннең авыруларына шифа бир. Йа Раббым, тазалык, саулык сорыйм», – дип, теләк телисе. Инде кырык бер чүмеч су алынып беткәч, чиләкнең өстен ару тастымал белән томалап куеп, өйгә алып кайтасың. Кайткач, тастымалның бер кырыен ачып, «Фатиха» («Әлхәм») сүрәсен, аннан «Әлиф, Ләм, Мим», «Аятел-Көрси» («Бәкара» сүрәсеннән) укып, суга өреп барасың. Аннан «Ихлас», «Фәлак», «Нәс» сүрәләрен укып, теләкләр теләп, тастымал белән янә каплап куясың. Гадәттә, таң суы белән мунчада юыналар. Мунчага кадәр чиләктә су ике-өч көн торса да, бер зыян да юк. Мунча яккач, аны җылынырга ләүкәгә алып барып куясың. Таң суы белән әйбәтләп юынганнан соң гына коеналар. Коенганнан соң суны өч тапкыр эчәләр дә.

Фатыйма апа тагын шуны да искәртте: таң суын теләсә кая түгәргә ярамый, догалар күп укыганлыктан, шифалы су санала. Шуңа да мунчада коенганда, табак эченә кереп басарга кирәк. (Су табакка агып төшә. Һәм түгәргә җайлы була.)

– Хәзер дә шулай таң суы ясыйсызмы? – дим әбекәйгә.

– Әйе, балалар, оныклар сорагач ясыйм. Күз тиюдән әйбәт инде. Кайвакыт үземә дә эшлим.

– Файдасын күрәсезме?

– Әлбәттә. Чын күңелдән дога кылып, ышанып сорасаң, файдасы була. Тотлыгучы балаларга да шулай эшлиләр иде. Ярдәме тиде.

– Ә тагын нинди авырулардан таң суы булышты?

– Авыру, дип. Салкын тию кебек авыруларга булышмый инде. Андый очракта дару кирәк. Бу күбрәк шул табиблар куя алмаган диагнозлар – күз тию, бозым-фәләннән ярдәм итә. Шайтаннар килмәсен өчен, дип тә әйтә иде әниләр. Кечкенә балаларны еш кына шулай таң суында юалар иде.

– Һәр ана кеше шулай баласын таң суында коендырса ярыймы? – дим.

– Ана кешенең намазда булуы шарт. Һәрхәлдә, әниләр безгә шулай дип әйтәләр иде. Таң суы булмаса, мондый су белән юындырганда да, ана кеше теләкләрен әйтеп, белгән догаларын укыса, файдасы зур. Ананың баласына кылган догасы кабул була, гел укып йөрергә кирәк.

...Кышкар – тарихка кергән авыл. 1774 елда биредә сәүдәгәр Баязит әл-Кышкари мәдрәсә төзи. Татар әдәбиятында, тарихында эз калдырган шәхесләр – Гатаулла Баязитов, Габделҗаббар Кандалый, Таип Яхин, Мотыйгулла Төхфәтуллиннар биредә укый. Нигездә, биредә дини гыйлем бирәләр. Илдә совет хакимияте урнашкач, 1918 елда мәдрәсә ябыла.

Авылда дини традицияләр, төрле ырымнар яшәүгә әлеге мәдрәсәнең дә өлеше тигәндер кебек тоелды. Россиянең төрле төбәкләреннән Кышкарга килеп укучы шәкертләр барыбер үзләре белән яңалык алып килгән бит. Һәм ул халыкка да сеңгән, көнкүрешенә кереп киткән булуы бик мөмкин. Мисал өчен, биредә тагын «Баш утырту», «Куркулык койдыру» кебек йолалар да яши. Бүген дә шуларны эшли белүче әбиләр бар. Иң мөһиме – алар чынлап та кемнәргәдер бүген дә ярдәм итә икән. Тагын әле әбиләр оныкларына «Дини дисбе» өйрәтә. Бу – ислам диненең төп кануннары турында ун сорау. Ул сорауларга җавапларны балалар кечкенәдән белеп үскән. Бүген дә Кышкар малай-кызлары аларга җавапны белә.

ТАТАРСТАН СӘМӘРКАНДЫ!

Автор: Руфия Фазылова

Инде аңлашылганча, «Татарстан» журналының июнь саны республика буенча сәяхәтләргә багышланды. Туристлар өчен иң кызыклы урынны эзли торгач, гаҗәп бер авылга тап булдык – Сәмәрканд! Әйе, әйе, Татарстанның үз Сәмәрканды бар! Әлмәт шәһәреннән 35 чакрым көньяк-көнбатыштарак, Нократ елгасы буенда урнашкан ул.

Фото: Александр Ефремов

СӘМӘРКАНД

ПОШИ, ТӨЛКЕЛӘР БЕЛӘН ЯНӘШӘ

Сәмәрканд 1921 елгы ачлык елларында оешкан. Кичүчат авылыннан өч бертуган ир бирегә килеп урнаша. Табигатьнең матурлыгын, җирнең уңдырышлылыгын күреп, соңрак бүтән гаиләләр дә күченеп килә. Сәмәрканд бүген Мәмәт авыл җирлегенә керә.

Авыл төрле яктан таулар, урманнар белән чолгап алынган. Йортлардан унбиш-егерме метр читтә урман башлана. Биредә барлыгы бер урам гына бар. Йортлар саны да күп түгел – унсигезләп кенә. Шуның берсендә ел әйләнәсе яшиләр, калганнарына җәен кайталар.

Авылга килгәч тә, бер мәл баш әйләнеп китте. Хәл алырга эскәмиягә барып утырдым. Бактың исә, кислород күп булганга шулай итә икән. Авылга килүче бүтән кешеләр дә «зарланган».

Иң әүвәл авылның хуҗасы – ел әйләнәсе биредә яши торган Сәхәповлар янында булдык. Рәфкать абый белән Нәзилә апа Сәмәркандта теркәлгән өч кешенең икесе. Хуҗалыклары зур – алтмышка якын чеби, егерме тавык, сарыклар, унике баш умарта. Шуңа өстәп биш эт, бер песи...

– Инкубаторыбыз бар, чебиләрне шунда чыгардык, – диде хуҗабикә.

Нәзилә апа авыл турында барысын да белә. Сәмәркандта туган кеше диярсең, югыйсә килен генә икән!

– Күрше Кичүчат авылында туган мин,- ди ул. – Балачакта Сәмәркандка җиләк җыярга килә идек, мондагы кебек матур табигать Әлмәт районында бүтән юк. 1977 елда Рәфкатькә кияүгә чыктым. Берничә ел Сәмәркандта яшәдек. Ул вакытта биредә утыздан артык йорт иде әле. Авылда райпо кибете бар иде, мин шунда эшләдем. Аннан соң Әлмәткә чыгып киттек, шунда гомер иттек. Ә җәйләрне Сәмәркандта уздырдык. 2014 елда исә бөтенләйгә бирегә күченеп кайттык.

Гаилә башлыгы Рәфкать абый – Сәмәркандта үскән бала. Әти-әнисенең йортын сүтеп, шул нигезгә яңа йорт җиткергәннәр. Бүген бирегә җәй буена оныклар, балалар кайта.

– Җәйне көтеп аласыздыр, кышларын Нәзилә апа белән икегезгә генә күңелсез түгелме? – дим.

– И, кышын да бик рәхәт, – дип елмая Рәфкать абый. – Карчык белән урман уртасында тик ятабыз. Әлбәттә, җәен күңеллерәк. Аннары, мич ягасы, кар чистартасы да юк...

Рәфкать абыйның капка төбендә тракторы тора, аны дүрт ел элек сатып алган.

– Механизатор булып эшләдем мин, – ди ул. – Картаеп барганда да тракторсыз булмады. Кышын аның белән кар чистартам, язын бакча эшкәртәм. Утын да алып кайтабыз...

Бу урында шуны әйтим – Сәмәркандка газ кермәгән. Кышын өйне утын белән җылыталар.

– Улыбыз электр казаны да алып кайтты үзе, – ди Рәфкать абый.

Әңгәмәдәшем Сәмәркандның куәтле чакларын бик хәтерләми. Бөек Ватан сугышына

1

2

1

– Әллә үлән эчүнең файдасы, каты авырганыбыз юк, – диде Нәзилә апа.

2

Гаилә башлыгы Рәфкать абый Сәмәркандта үскән бала.

3

Гөлсинә Филипповская. Заманында нәкъ менә аның бабалары авылга нигез салган.

4

Тарасовлар авылда иң күп умарта тотучыларның берсе – егерме ике оя кортлары бар.

5

Валерий күп итеп сатуга савыр (туя) агачлары утырткан.

кадәр биредә бөтен районга атаклы «Социализм» колхозы оеша. Хәтта мәктәп тә ачылган була.

– Без инде ул мәктәптә укымадык, ә күрше Мәмәт урта мәктәбенә йөреп укыдык, – ди Рәфкать абый.

– Ә сез үскәндә авылда балалар күп идеме? – дим.

– Уннан артык иде. Сәмәрканд беркайчан зур авыл булмаган. Документларда сакланып калганча, 1938 елда авылда 121 кеше яшәгән. Инде ул чагында колхоз аякка баскан була. 1949 елда да 121 кеше исәпләнә әле. Ә менә 1958 елда 64 кеше генә теркәлгән. Шуннан инде халык саны кимегән.

Сәхәповлар белән ихаталарын карап чыктык – калайдан яңа койма тотып яталар. Бакчалары зур, анда ни генә үсми!

– Бик ошый монда, – диде хуҗабикә. – Октябрь азагына кадәр әле авылда кеше була. Язын кар эри башлагач тагын кайталар. Кышын атна саен балалар кайтып йөри. Телефон бар, гел аралашып торабыз. Бабай белән телевизор карап, тәмлүшкәләр ашап тик ятабыз. Тигезлектән генә аермасын, рәхәт яшибез.

Атнасына ике тапкыр күрше авыл кибетенә барып, ризык алып кайталар. Рәфкать абыйның әле УАЗ машинасы да бар. Нәзилә апа аш-суга уңган, төрле ризыкларны әзерләп кенә тора икән.

Хуҗабикә үләннәр дә киптерә, ел әйләнәсе шифалы чәй эчәләр. Туганнарына, авылдашларына да җитә.

– Әллә үлән эчүнең файдасы, каты авырганыбыз юк, – диде Нәзилә апа. – Ә болай әйдә бөтен төрле дару тора, дөнья хәлен белеп булмый, балалар алдан хәстәрен күреп куя.

Сәхәповларның бакча яны зоопарк кебек – әледән-әле пошилар, кабан дуңгызлары, төлкеләр, куяннар «кунак була».

– Бүген генә ана поши баласы белән арттагы елгадан су эчеп тора иде, – диде Рәфкать абый. – Кышын төлкеләр капка төбенә үк килеп утыра. Тик әйтмәгәнем булсын, кош-кортларга, малларга тигәннәре юк. Алар инде безгә ияләнеп беткән...

«БАБАМ АВЫЛГА НИГЕЗ САЛГАН»

Сәмәркандның тагын бер хөрмәтле кешесе – Гөлсинә апа Филипповская. Заманында нәкъ менә аның бабалары авылга нигез салган. Сиксән ике яшен тутыручы әби туган нигезен онытмый. Ел саен бирегә кайтып, күп итеп яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәкләр утырта, кош-корт үстерә. Быел үрдәкләр алган.

– Шушы нигездә тудым, үстем, – диде Гөлсинә апа. – Аннан Үзбәкстан якларына чыгып киттем. Кияүгә чыктым. Төрле җирләрдә яшәргә туры килде. Хәзер менә кышны кызларым янында – Әлмәттә уздырам, ә язын монда кайтам. Көзгә хәтле торам. Кышын Сәмәрканд төшкә керә, бик сагынам. Аннары Нәзиләгә елап шылтыратам. Күршеләрем бик әйбәт, бер гаилә кебек яшибез. Кышын кайтсак, Нәзилә барыбызны елмаеп каршы ала, бәлешләр пешереп көтеп тора.

– Сез үскәндә авыл зур идеме? – дим.

– Зур иде. Башлангыч сыйныфны Сәмәркандта укыдым. Гади агач йорт иде ул. Мин 1939 елда туган бала, сугыш вакытын бик яхшы хәтерләмим. Ә менә сугыштан

соң авылның бик матур яшәгәнен беләм. Безнең «Социализм» колхозын үрнәк итеп куялар иде. Бер дигән сыер, дуңгыз фермалары! Миллионер колхоз саналды. Игенчелектә гел алдынгы урында бара идек. Тик менә алтмышынчы елларда безне күрше «Победа» колхозына куштылар. Бөтен малларны күрше авылга төяп киттеләр. Менә шунда авылдан күп кеше китте. Эш бетте бит. Башлангыч мәктәп тә ябылды.

– Ә ни өчен колхозларны берләштерделәр?

– Төгәл генә әйтә алмыйм, ул вакытта мин авылда яшәми идем. Монда бит җирләр яхшы, уңдырышлы. Күрәсең, кызыкканнар. Бәлки җир эшкәртергә халык та җитеп бетмәгәндер. Авыл кешеләре шундый миллионер колхозның бетерелүен бик авыр кабул итте.

Гөлсинә апа ачык күңелле, җор телле әби. Без килгәндә күп итеп керләр юган иде.

– И, матур күлмәгемне дә юдым бит, – дип куйды. Шулай да егерме минутлап фотога төште. Әле чәчәкләре янына килеп баса, әле өй каршына...

– Йортыгыз урам башында ук икән, курыкмыйсызмы? – дим.

– Юк, нәрсәдән куркасың?! Авылга чит кешеләр килми, ерткыч хайваннар ишек алдына керми. Шул еланнар булырга мөмкин инде. Быел алар бик күп, язын табор белән йөрделәр. Әйтмәгәнем булсын, безгә тими алар. Күпме яшәп тә, авылда елан чагу очрагын белмим. Елан бит ул, үзенә тимәсәң, чакмый. Шуңа күрә сез дә аяк астыгызга карап йөрегез.

Гөлсинә апа безне Рәхим бабай чишмәсенә алып төште. Тау астына урнашкан ул, суы йомшак икән. Чишмә авылның яшәү чыганагы, эчәр суны халык шуннан ала.

– Рәхим бабай кем булган? – дим.

– Авылның аксакалы. Минем бабайлар аны бирегә чакырып китергән. Йорты чишмә янында булганга, күрәсең, чишмәне дә карап торган. Хөрмәтле кеше дә булган. Шуңа күрә Рәхим бабай исемен мәңгеләштергәннәр.

Чишмәне заманында нефтьчеләр шефлыкка алган булган. Баскычлар ясап, тимердән утыргычлар эшләп куйганнар. Тик хәзер бу традиция югалган – нефть оешмалары шәхси кулларга күчеп беткән.

– Чишмә юлын кияү кайтып чабып китте, – диде Гөлсинә апа. – Өч кызым, өч киявем бар минем. Балалар да авылны бик ярата. Киявем бер дигән яңа мунча салып бирде.

Авылга су кермәгән. Тик халык җаен тапкан – Рәхим бабай чишмәсеннән насос белән су суырталар. Бакчага сибү өчен кайберәүләр Нократ елгасыннан да ала икән.

КОНДРАТ БАБАЙ ТАРИХЫ

Сәмәрканд чын татар авылы. Ләкин авылда берничә рус гаиләсе дә яши. Шулар арасыннан Тарасовлар бирелә иң озак яшәүчеләр. Гаилә башлыгы – Кондратий Дәдәйне авыл кешеләре яратып: «Кондрат бабай» дип йөртә. Тормыш иптәше Серафима түтине дә авыл кешеләре күптән үз иткән. Күңелләре шикелле, капкалары да гел ачык аларның.

– Сәмәркандка килгәнгә утыз ел булды, – диде Кондрат бабай. – Ә кышын карчыгым белән Әлмәттә яшибез. Өч улыбыз бар, алар да җәйне күбрәк монда уздыра.

Тарасовлар бик зур булмаган йорт салганнар. Уртанчы уллары Валерий каршыга заманча тагын бер йорт төзеп куйган. Гаиләсе белән ул да җәйләрен бирелә яшәргә җыена икән. Валерий күп итеп сатуга савыр (туя) агачлары утырткан.

– Сәмәрканд турында ничек белдегез? – дидем гаилә башлыгына.

– Мин Әлмәттә тракторда эшләдем. Шуннан бу якка эшкә җибәрделәр. Сәмәркандны күрдем дә Серафимага кайтып әйттем. Дача өчен бик яхшы дигән урын таптым, дидем. Шуннан менә йорт салдык. И, моннан да матур урын юк. Тәүлек буе кошлар сайрый бит.

Тарасовлар авылда иң күп умарта тотучыларның берсе – егерме ике оя кортлары бар. Балны саталар икән.

– Кортлар асрау өчен бер дигән урын бу, – диде Кондрат бабай. – Шуңа да һәр ике йортның берсендә умарта бар. Бөтен кеше, иң тәмле бал сезнең авылда, ди. Сәмәркандка мин кар эрегәнче үк кайтам, кортларны карыйм. Аннан кар яуганчы диярлек торам. Дөресен генә әйткәндә, үземне шушы авыл кешесе итеп хис итәм.

Кондрат бабай белән Серафима түти кунакка чакырып калды: «Августта, бал аерткач килегез», – диделәр. Бәлки килербез дә, чөнки сәбәбе бар – Мәмәт авыл җирлеге башлыгы Илсөя Зөбәерова: «Августта зурлап Сәмәркандның йөз еллыгын билгеләп узачакбыз», – диде.

...Авылда иң гаҗәпләндергәне – урам тулы кеше. (Без башта Мәмәт авылында булган идек. Нинди зур авылда биш-алты кеше очраттык. Ә бирелә...) Бала-чага туп белән уйный, кемдер бакчада эшли, икенчеләр чишмә буенда йөри, өченчеләр капка төбендәге үләнне чаба. Туктаусыз кошлар сайрый... Бөтенләй икенче дөньяга барып килгән кебек булдык.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Сәмәрканд авылы яшәүче Рәфкать Сәхәпов:

– Сәмәрканд – иң бай, иң көчле, иң тотрыклы дигән мәгънәне белдерә. Җирле халык яңа оешкан авылның нәкъ менә шундый булуын теләгәндер. Документларда авыл 1925 елда оешкан дип әйтелә. Ләкин бабайлар авылга алдарак, 1921–1922 елларда нигез салынган, дип сөйли иде. Күрәсең, аны кешеләр килеп төпләнүгә үк теркәмәгәннәр. Сәмәркандка нигез салучылар Кичүчаттан өч бертуган була. Аларның исемнәре – Мөхәммәтша, Дәүләтша, Мәрдәнша.

КАЗАНДА МОДАЛЫ МАЙ АЕ: «ТУКАЙ ЕГЕТЛӘРЕ»ННӘН ХРОМОСОМА»ГА КАДӘР

Россиянең 20 шәһәреннән зиннәтле мода коллекцияләре күрсәтү, пандемиядән соң дөньяда моданың ничек үзгәрүе турында фикер алышу, татар традицион мәдәниятен өйрәнүче Римма Кашаповадан төрки костюм тарихына алып кергән һәм борынгы төрки киемнәрнең хәзерге модада чагылышын күрсәткән лекция – болар барысы да Казанда май аенда оештырылган Volga Fashion Week халыкара мода атналыгы кысаларында узды.

ТУКАЙ ЧОРЫ КОСТЮМНАРЫ

Volga Fashion Week атналыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Елена Корункова, Ульяновск шәһәре:

– Искиткеч булды! Урыны, вакыты, дизайнерлары, куелыш режиссурасы, кунакларның хистойгылары – барысы да чып-чын тылсым! Римма Кашапова үз презентациясендә милли стильнең аны кулланучы өчен бер абруй, дәрәҗә чагылышы икәнлеген дә ассызыклады. Бу яктан, модельер Руслан Габовның Тукай чорындагы ир-атлар костюмнары коллекциясе ачыш, яңалык булды!

ТАТАРСТАНГА ГАШЫЙК

Алиса Альтфайзер, эшмәкәр ханым, Мәскәү:

– Бәйрәм өчен бик зур рәхмәт! Җитеннән һәм башка табигый тукымалардан тегелгән милли костюмнар тәкъдим итүчеләре күңелемне яулап алды. Казанга күп тапкыр килгәнем бар, тик нәкъ менә шушы сәфәрдән соң Татарстанга гашыйк булдым. Халык күп гасырлык тарих һәм канун-йолаларны хөрмәт итә. Яшьләр кызыклы, аңлы һәм бик тәрбияле. Мөгаен, монда ир-атлар иң матурлардандыр:). Искиткеч матур киенгән туташлар һәм ханымнар. Игелекле кешеләр!

ТАТАР КЫЗЛАРЫ БИК ТӘРБИЯЛЕ

Елена Коробейникова, «Россия дизайнерлары берлеге» Гомумроссия иҗтимагый оешмасының Төмән төбәк бүлеге рәисе, кием дизайнеры, Төмән шәһәре:

– Программаның югары дәрәҗәдә оештырылуын билгеләп үтим. Сәхнә арты – галәмәт зур хезмәт ул! Модель агентлыгы да эшен яхшы башкарды. Манекенчы кызларның килешкилбәтләренә тел тидерерлек түгел, өстәвенә, алар бик тәртипле дә. Мөгаен, бу төбәкнең бер үзенчәлегедер – татар кызлары бик тәрбияле.



Фото: Александр Ефремов

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store
Google Play

Реклама 6+

#ТатарстанБуйлапСәяхәткә